Очышта
Казан вертолет заводында бер көн

Дөньяда иң киң кулланыла торган «Ми-8» вертолетлары Казан вертолет заводында җыела. Очкычларны күргәнебез булса да, алар турында күп ишетсәк тә, ничек җыелганлыгын күпләр белми. «ШК» журналистларына исә бу серне чишәргә ризалаштылар.

11 БИТ

«Шәһри Казан» бүләк өләшә

Абунәчеләргә бүләккә – алмагач үсентеләре.

8 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 13.04.2017 | № 39 (5801)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

БАЗАР КАНУННАРЫ
Чатырлы ярминкәләр ничек эшли?

Чатырлы ярминкәләрдә кече формалы хуҗалыклар һәм бакчачылар сатар дип фаразланган иде. Татарстан Президентына андагы эш тәртибеннән зарландылар. Фермерларга нәрсә ошамый, алар нәрсәдән риза түгел? «ШК» журналисты ярминкәләр эшчәнлеге белән кабат танышып кайтты.

7 БИТ

Дамир Бәдриев фотосы

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга	69 сум 31 тиен
3 айга	207 сум 93 тиен
6 айга	415 сум 86 тиен



Ташламалы бәядән язылып кал!

11-21 май, 2017

Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен	1 айга
427 сум 14 тиен	3 айга
854 сум 28 тиен	6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

АРЧА

«Казан арты» тарихи-этнография музеенда халык шагыйре Габдулла Тукайга багышланган күргәзмә эшли. Экспозициянең үзәгендә – шагыйрь фотосы, аның беренчә томлы әсәрләре урнаштырылган. Анда Габдулла Тукайның гына түгел, ә Арча төбәгеннән чыккан башка бик күп язучыларның да китаплары урын алган.

ЗӘЙ

Бу атна башында Зәй районы аграрийлары язгы кыр эшләрен башлап җибәрде. Көзге культураларны тукландыруга быел да, беренчеләрдән булып, «Нива» җаваплылыгы чикләнгән ширкәте керешә. Кыр эшләренә старт бирүдә район башлыгы Рәзиф Кәримов, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Атлас Галиәхмәтов, идарә белгечләре, агрофирма һәм бүлекчә җитәкчеләре, агрономнар катнашкан.

ЧИРМЕШӘН

Районның яшь рәссамнары ясаган картиналар аукционда сатыла. Мәсәлән, балалар сәнгать мәктәбен тәмамлаган Миләүшә Гайнетдинованың «Зима» («Кыш») картинасын «Энерготехсервис» җәмгыяте директоры Илдар Нуруллин 1500 сумга алган.

ЧАЛЛЫ

Чаллы татар дәүләт курчак театры коллективы, «Алтын битлек» милли театр премиясе кысаларында, «Сак-сок» спектаклен күрсәтте. Спектакль Мәскәү Курчак театрының Зур залында барды. «Сак-сок» бәетенә нигезләнеп куелган спектакль – Илгиз Зәйниевнең курчак театрындагы беренче эше. Спектакль үзенчәлекле куелышы белән үзенә җәлеп итә. Коллектив аны Казанда «Һөнәр» фестивалендә тәкъдим иткән иде. Спектакль «Тантана-2017» театр премиясендә «Ел вакыйгасы» буларак танылды.

ӘЛКИ

Кыргый җанварларны котыру чиренә каршы вакциналау өчен, Әлки районына 10 мең данә препарат кайткан. Район ветеринария берләшмәсе баш табибы Камил Хәйруллин санитар-эпидемиягә каршы комиссия утырышында хәбәр иткәнчә, ветеринария хезмәткәрләре егерьлар, аучылар белән берлектә «тәмле» вакциналарны төлкеләр, башка кыргый җанварларның өннәре тирәләренә таратып чыга. Бу эш 30 апрельгә кадәр башкарылачак.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

АЛЛАГА ТАПШЫРДЫК!

Зөлфия Хәлиуллина фотосы

Татарстан аграрийлары язгы кыр эшләренә керешә

Район кырларында иң беренче чиратта эшләнелә торган эшләр – уҗым культураларын тукландыру, тырмалау башланды. Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Николай Титов хәбәр иткәнчә, быел чәчүлек мәйданнары 2,9 гектарга җитәчәк. Җитәкче чәчү мәйданнарын кыскартырга җыенмаулары турында да белдерде.

Николай Титов чәчү техникасын кабул итү буенча саллы эш башкарылганын билгеләп узды. Шулай ук авыл хуҗалыгы техникасын кабул итүне кабаттан уздырганнар.

– Әйтергә кирәк, бүген авыл хуҗалыгы техникасының әзерлеге, узган елга караганда, күпкә югарырак. Быел язгы кыр эшләрендә республикада 11 мең трактор, 615 чәчү комплексы, 6,3 мең чәчкеч, 5,3 мең культиватор, 1 меңнән артык күп функцияле туфрак эшкәртү агрегатлары эшкә җигеләчәк. Бу – чәчү кампаниясен билгеләнгән срокларда башкарырга мөмкинлек бирә. Ремонт эшләре уздыру өчен, республикада 700гә якын төзекләндерү урыны, авыл хуҗалыгы машиналарын төзәтү һәм көйләү өчен 750дән артык пункт бар. Техника өчен кирәк-ярак кайтарту да күзәтү астында. Шул ук вакытта фермерларга ташламалы кредит бирү мәсьәләсе әле дә булса авырлык белән бара, – диде ул.

Сездә ни хәлләр?

Атлас Галиәхмәтов, Зәй районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы:

– Зәй районының «Нива» җаваплылыгы чикләнгән ширкәте, иң беренчеләрдән булып, язгы кыр эшләрен башлап җибәрде. Ширкәттә кырга аммиак селитрасын ике «Туман» агрегаты тарата. Агрегатны ашлама белән тәэмин итүдә өзеклек юк: ашлама 1 гектар мәйданга 1 центнер исәбеннән кертелә. Агрегатлар, туфрак җебегәнче, дип, иртәнге сәгать 2дән эшкә керешә. Бер-ике көннән алар сафын өч очкыч тулыландырачак. Бу исә эшне күпкә тизләтергә мөмкинлек бирәчәк. Шунысы игътибарга лаек, быел яз үзенчәлекле, басуларда ерганаклар ярып гөрләвекләр акмый, эрегән кар суы туфракка сеңеп бара, моның белән ашлама чәчүлекләр дә тиз үзләштерелә.

Рамил Зарипов, Азнакай районының «Марс» хуҗалыгы җитәкчесе:

– Быел Азнакайда кар күп яуды. Бүген-иртәгә иң беренче чиратта арыш җирләренә чыгачакбыз. Башка районнар белән чагыштырганда, безнең якларда эшләр иртәрәк башлана, чөнки җирләр тизрәк өлгерә. Әзерлек барышында авырлыклар, проблемалар да булды, әмма без елап утыра торганнардан түгел, аларны җиңеп чыктык. Техникаларны карадык, ашламаларның барысын да кайтарып беткәнбез. Минераль ашламалар гектарга 50 кг исәбеннән әзерләнде. Техника да җитәрлек. Кырга 20 техника чыгачак. Кыскасы, язгы кыр эшләренә без тулысы белән әзер. Исән-имин эшләргә дип дәртләнеп торабыз.

Шәһәр кәефе

СӘЙДӘШ ШӘРАПОВ,
артист:

– Казанда җәйге чорда шимбә көннәрендә кече Сабантуйлар үткәрелсен иде. Анда көрәш оештырырга кирәкми дә. Урам театры эшләсен, картиналар һәм сувенирлар сатылсын, китап сәүдәсе булсын. Бер түгәрәктә – биюләр, икенчесендә – ГТО тапшыру. Туристлар өчен дә кызыклы булыр иде бу.

Баянда, курайда, гитарада уйныйм. Татар егетләре гармунда уйнарга өйрәнсеннәр иде. Пирамидалар турында күп укыдым, инде Мисырга барырга хыялланам.

НЕЛЛИ ФӘҮХЕТДИНОВА,
студент:

– Башкортстанның Туймазы районында туып-үстем. Казанның югары уку йортлары бик дәрәҗәле. Монда укытучы белгечләренә укыйм. Казанда мәдәният дөньясы да гөрләп тора. Әнием хәлемне белергә килгән чагында, һичшиксез, театрга яки концертка бара. «Казанның һәр спектакле – зур истәлек ул», – ди. Биергә яратам, бию түгәрәгенә йөрим. Хыялым – матур гаилә кору.

НИНА МИТИНА,
пенсионер:

– Казан баласы мин, шушында тудым, шушында гомеремне кичерәчәкмен. Англиягә кызым янына кунакка баргач, бер-ике көндә Казанымны сагына башлыйм. Монда чүп-чары да күңелгә якын. Ләкин шәһәребездә чисталыкка җаваплырак карасак иде. Санитар икеайлыкның беренче ае инде узып бара, ә урамнарны дәррәү җыештыру артык сизелми. Бакчага барып, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр үстерергә ашкынам.

ЭЛЕНА ФӘТХУЛЛИНА,
студент:

– Энергетика өлкәсе инженеры булачакмын. Мин үзем Оренбург өлкәсеннән. Казанда чын мәгънәсендә татарга әверелдем. Милләт сулышы, театрлар һәм концертлар. Татарча китаплар укыйм, милли ашларыбызны пешерергә өйрәндем. Татарстаннан читтә бу мөмкинлекләр азрак шул. Изге Болгарга барырга ниятләп куйдым. Борынгы һәм шул ук вакытта заманнан калышмаучы Казан – искиткеч! Укуны тәмамлагач, Казанда каласым килә.

АЯЗ ХӘСӘНОВ,
журналист:

– Красноярск шәһәрендә туганмын. Мин күкрәк баласы чагында, гаиләбез Казанга күченеп кайткан. Шунлыктан үземне тулысынча казанлы дип саныйм. Европа берлеге илләре белән дә танышып кайтсаң ярар иде. Кремль янында, Бауман урамында хәер сорашучыларның туристларга бәйләнүләрен шулкадәр яратмыйм. Хәер соранырлык хәерчелектә яшәмибез ләбаса. Эшләсәң, эш бар. Полиция хезмәткәрләре моңа юл куймасын иде.

«Кызыл әтәч» уйный

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Бу көннәрдә Казанда көн туды исә янгын. Кичә дә башкала үзәгендә ике тарихи бинага ут капты. «Бертуган Крестовниклар» фабрика-сәүдә ширкәте йортында чыккан янгын турындагы мәгълүмат 11.59 сәгатьтә килеп ирешкән.

Янгын бинаның чарлактагы катында чыккан. Казанның Габдулла Тукай урамындагы 113нче санлы бу йорты элекке механика-технология техникумы бинасы буларак та билгеле. Янгын вакытында бина эчендә ике каравылчы да булган, алар чыга алган. Зыян күрүчеләр хакында мәгълүмат юк. Янгынның мәйданы 1200 квадрат метрны тәшкил иткән.

Архитектура һәйкәлендә чыккан янгын очрагын тикшерү эше Казан шәһәре Совет районының прокуратурасына йөкләнелде. Күзәтү идарәсе мәдәни мирас объектын саклау буенча күрелгән чараларны, бинаны кулланганда янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү дәрәҗәсен өйрәнәчәк. Канун бозу очраклары ачыкланган очракта, прокурор ягыннан тиешле чаралар күреләчәк.

Кичкә таба Казанның Ш.Мәрҗани урамында урнашкан 44нче йортына да ут кабуы билгеле булды. Анысы – төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас.

Дүшәмбе Аракчино бистәсендә урнашкан барлык диннәр гыйбадәтханәсе янган иде. Анда рәссам Илдар Хановның уң кулы, элеккеге ярдәмчесе Мансур Зиннәтов һәлак булды. Кичә янгын сүндерүчеләр ут чыккан бинада өч янып киту чыганагы табылу турында хәбәр итте. Әлеге фаҗиганең икенче көнендә Кремль яр буенда да янгын чыгып, төзелә башлаган корылма көлгә әйләнде.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстан

Башкортстан умартачылары яңа сезонны ачкан. Бу көннәрдә алар, кышлаудан соң, умарта өеннән умарталарны алып чыга, бал кортлары ояларын карый һәм, кирәк булган очракта, аларга ашарга бирә. Бу хакта «Башинформ» хәбәр итә.

Сезон башланыр алдыннан, Чишмә бистәсендә дүрт район умартачылары һәм авыл хуҗалыгы идарәсе вәкилләре, ветеринария хезмәте катнашында җыелыш узган. Умарталар, гомумән алганда, имин кышлаган. Кызганыч, кайбер хуҗалыкларда югалтулар бар. Умартачылар белдерүенчә, сәбәп һава шартлары начар булуда түгел, ә умарталарны кышка тиешенчә әзерләмәүдә.

Чувашия

Чувашиядә мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен вакансияләр банкы формалашкан. Хәзерге вакытта монда 350 кешегә төрле тәкъдимнәр каралган. Чувашия Республикасының Хезмәт министрлыгы башлыгы Сергей Димитриев әйтүенчә, вакансияләр базасы, оешмалар һәм медик-социаль экспертиза учреждениеләре катнашында, һәрдаим яңартыла. Шулай итеп, эш эзләүчеләргә тернәкләндерү программасын яңарткан вакытта ук эшкә урнашу мөмкинлеге каралган. Статистика мәгълүматларына караганда, хәзерге вакытта Чувашиядә биш меңнән артык инвалид төрле урыннарда хезмәт куя.

Мари Эл

Мари Эл республикасы башкаласы Йошкар-Олада Җиңү көне һәм Яз бәйрәмнәренә әзерлек башланды. Шушы уңайдан шәһәр бинналары, күперләр, юл чишелешләре, мәйданнар һәм урамнар флаглар, төрле композицияләр, паннолар белән бизәләчәк. Шәһәр администрациясе әлеге эшләрне 28 апрельдә тәгәлләргә планлаштыра.

Казан мэры, «Рубин» футбол клубы президенты Илсур Метшин «Известия» газетасына биргән әңгәмәсендә

Әгәр «Рубин» хәзерге сезон нәтиҗәләре буенча Еврокубокка эләксә, мин сөенечтән чәчемне пеләшкә кырдырачакмын.

Лифтларга яңа сулыш «өреләә»

2017 елда Россиядә 18 мең лифт алыштырылачак, шуларның 5 меңе – ашыгыч рәвештә, ягъни тизләтелгән алыштыру контракты нигезендә башкарылачак. Бу хакта Россия Төзелеш министрлыгы карамагындагы Иҗтимагый совет рәисе Сергей Степашин җиткерде, дип хәбәр итә «Российская газета».

– Бу эш йортлардагы меңләгән кешенең куркынычсызлыгын тәэмин итәргә ярдәм итәчәк, – дип билгеләп үткән Степашин.

Сүз күп фатирлы йортларда яшәүче ярты миллион халыкның яңа лифтлардан файдаланачагы турында бара. Йортчыларга лифт алыштырган өчен түләргә кирәкми. Тизләтелгән алыштыру буенча кредит проекты фатир хуҗаларыннан өстәмә финанс чыгымнары сорамый.

Проектта бары 23 төбәк катнаша. Лифтлар алыштыруга бюджеттан тыш 30 млрд сум акча тоту ниятләнелә. Чагыштыру өчен, 2016 елда – 12,5 мең, 2015 елда 9,5 мең лифт алыштырылган.

Россиядә барлыгы 440 мең лифт бар. 130 меңе инде үз вазифаларын башкарган һәм алыштыруны көтә.

Космонавтика көнендә ял итәрбезме?

Россия Дәүләт Думасында Космонавтика көнен – 12 апрельне ял көне итү тәкъдиме булган. Бу хакта Дәүләт Думасының Физик культура, спорт, туристлык һәм яшьләр эшләре буенча комитет башлыгы Михаил Дегтярев (ЛДПР) фракция исеменнән пленар утырышта чыгыш ясаганда җиткергән, дип хәбәр итә «Российская газета».

– Космонавтика көне – милли бәйрәм, безнең интеллектның җиңү символы булырга тиеш, – дип белдергән парламент әгъзасы. Моннан тыш, ул бу көнне яшьләргә космик җиңүләр турында фильмнарны бушлай күрсәтү, космоска багышланган күргәзмәләргә түләүсез керү мөмкинлеген булдыруны да тәкъдим иткән.

Искәртеп үтик, бәйрәм 1962 елның 9 апрелендә дөньяда беренче тапкыр кешенең галәмгә очу хөрмәтенә билгеләнгән. Әмма бүгенгә кадәр ул ял көне итеп билгеләнмәгән. Михаил Дегтярев сүзләренчә, 1961 елның 12 апреле – масштаблы вакыйга һәм Юрий Гагарин белән Сергей Королев исемнәре мең, 10 мең елдан соң да онытылмаячак.

ТОП – 3

«РОССИЙСКАЯ ГАЗЕТА» язганча, Россия Президентын сайлау көне үзгәртелергә мөмкин. Әлеге дата 2018 елның 11 марты булыр дип тәгаенләнгән иде, хәзер аның 18 мартка күчерелү ихтималы бар. 11 март – 8 мартка якын көн. Бездә, гадәттә, ял көннәрен күчерү практикасы бар, бу исә сайлау алды эшләренә комачаулык тудырырга мөмкин, дип саный канун чыгаручылар – проект авторлары Андрей Клишас белән Анатолий Широков.

ТАТАРСТАНДА тагын бер шәһәр барлыкка килде. Дәүләт Советының дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты Кукмарага шәһәр статусын бирү турындагы канун проектын һәм әлеге уңайдан республика канунына үзгәрешләр кертүне хуплады, дип хәбәр «Татар-информ». Район башлыгы Сергей Дмитриев сүзләренчә, әлеге проект буенча фикер алышуда халыкның 70 процент чамасы катнашкан, шуларның 87 проценты тәкъдимгә ризалык белдергән. 2016 елның 1 гыйнварына Кукмара бистәсендә 17 694 кеше яши.

КАЗАННЫҢ «Кол Шәриф» мәчетендә Татарстанның дини һәм фәнни бергәлек вәкилләре катнашында татар ханнарының җәсәдләрен җирләү турындагы мәсьәләләрне тикшерүгә багышланган җыелыш уздырылды. Ханнарның җәсәде 1977 елда Казан Кремле тирәсендә бер төркем археологлар тарафыннан табыла. Тикшеренүләр нәтиҗәсендә, аларның Казан ханнары Мәхмүт һәм Мөхәммәт Әмин җәсәде булуы ачыклана. Дин һәм фән эшлеклеләре җирләү буенча эшләрне хан гаиләсенә тиешле хөрмәт һәм олылау күрсәтеп башкару кирәклеге турында белдерде. ТР Диния нәзарәте Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов исламда да, башка диннәрдә дә, кешене вафатыннан соң җиргә иңдерүнен кичекмәстән үтәлергә тиешле бер шарт булып торуын һәм моның ата-бабаларыбыз алдында изге бурыч булуын җиткерде. Ханнарның җәсәден җиргә иңдерү мәсьәләсен карау киләсе утырышларның берсендә дәвам итәчәк.

АВЫЛ

Эх, бәрәңгесе дисеннәр...

Көннәр җылытты, авыл халкы чәчүлек бәрәңгесен баздан чыгарып, кояшта җилләтеп алу җаен карый башлады. Соңгы елларда бәрәңге уңышы бер дә сөендерми. Берәүләр моның сәбәбен җәйнең коры килүе белән бәйләп караса, икенчеләр бәрәңге орлыгының начар булуыннан күрә. Шуңа да хәзер күпләр аны сатып алу җаен карый. Орлыкның кайсы сортын сайларга, гомумән яхшы уңыш алуның сере тагын нәрсәдә? Әлеге сораулар белән без Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтының үсемлекләрне саклау үзәге җитәкчесе, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы Фәния Җамалиевага мөрәҗәгать иттек.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Фәния Фәйзрахмановна, ни өчен соңгы елларда бәрәңге уңышы начар була башлады?

– Моны бер җөмлә белән генә әйтеп булмый. Иң беренче чиратта бәрәңге орлыгының начар булуы, бакчада чәчү әйләнеше ясамау яки аны ял иттермәүгә дә бәйле. Бәрәңгенең төрле инфекцияләргә, авыруларга бирешүчәнлеге дә уңышны бермә-бер киметә. Уңышның түбән булуының тагын бер сәбәбе, безнең карашка, җәйнең коры килүеннән һәм туфрак кибү белән бәйле авырулардан. Шуңа да сугарылмый торган җирдә Роко сортын чәчәргә, орлык материалын яңартып торырга киңәш итәбез.

– Безнең шартларга яраклаштырылган тагын нинди сорт бәрәңгеләрне утыртырга тәкъдим итәсез?

– Шәхси хуҗалыклар өчен иң яхшысы, кабатлап әйтәм, Ү-вируска һәм фузариозга тотрыклы булган Роко сорты. Ү-вируска бөтенләй бирешми торган Ароза, Кортни, Регги, Юбилей Жукова сортлары өстенлек бирегез. Удача, Невский, Зекура сортлары да яхшы, әмма аларны сугарып торырга кирәк. Ни өчен дигәндә, корылыкта алар фузариозга бирешә. Импала, Ред Скарлетт, Жуковский ранний дигән сортларны шулай ук сугарып тору зарур. Моннан тыш, бу сортларның орлыгын һәр ике-өч ел саен алыштырып торыгыз, чөнки әлеге дә баягы Ү-вируска бирешүчәннәр.

– Корылыкка чыдам булган нинди сортлар бар?

– Корылыкка чыдам сортлар – Роко һәм Винета, эссегә бирешми торганнардан Кортни белән Реггины әйтә алам.

– Орлыклык бәрәңге кибетләрдә дә сатыла, аларны ничек сайлап алырга?

– Бәрәңге орлыгы бернечә категориягә бүленә – супер-суперэлита, суперэлита, элита, беренче, икенче һәм өченче репродукция. Югары репродукция, ягъни суперэлита, элита категориясенә кергәннәргә өстенлек бирегез. Орлыклык бәрәңгене орлыклар сатыла торган кибетләрдән алырга тырышыгыз.

– Әңгәмә башында, җирне дә ял иттерергә кирәк, дигән идегез?

– Авыл җирендә бәрәңгене еллар буе гел бер бакчага утырталар, җир ял итми, шуңа күрә чүп үләннәре дә котырып үсә, төрле авырулар барлыкка килә. Бакчаны дүрт өлешкә бүлеп, шуның бер өлешенә генә бәрәңге чәчәргә кирәк, калган өлешләрен ял иттерәсез. Бәрәңге – бөртеклеләр – борчак – рапс схемасын кулланырга була. Шәхси хуҗалыкларда бу бик үк уңайлы түгел, шуның өстенә бакчаның мәйданын да киметүчеләр күп. Шуңа да бакчаны һич югы икегә бүлегез. Бер өлешенә – бәрәңге, икенче өлешенә клевер (люцерна) чәчәсез. Ике-өч ел шулай утырткач, урыннарын алыштырасыз.

– Чүп үләннәреннән ничек арынырга?

– Бәрәңгене утырткач һәм утыртып ике атна үткәч, ягъни тишелеп чыкканчы тырмалагыз. Бу чүп үләннәреннән 80 процентка арынырга булыша. Бәрәңге төбен күмгәндә дә чүбен утап барыгыз. Чәчү әйләнешен ясау да ярдәм итә. Чүп үләннәре һаман шулай күп булса, көзен гербицидлар (глифосат) белән эшкәртегез. Утаган үләннәрегезне межада калдырмагыз. Алар күпшәкләндерелгән туфракта яңгырдан соң кабат үсеп китә ала.

– Колорадо коңгызына каршы ничек көрәшергә?

– Хәзерге вакытта бәрәңгене эшкәртеп утыртмыйча, аңа каршы торып булмый. Утыртыр алдыннан бәрәңге орлыгын «Престиж» препараты белән эшкәртегез. Әмма аны фәкать августта алыначак бәрәңге өчен генә кулланыгыз. Ул вакытка кадәр агуы чыгып бетә аның. Химик матдәләр бөтенләй чыгып бетсен өчен, 60 көн кирәк. Иртә өлгерешле сортларга аны кулланмагыз. Әлеге препарат орлыкны эшкәртүче кешегә һәм әйләнә-тирәгә куркыныч тудырмый. Бер тонна бәрәңге өчен 5-6 литр суга 0,8 литр «Престиж» салыгыз. Бәрәңгене яшелчә сеткасына тутырып, пленка өстенә куеп эшкәртегез. Катнашманы өстән сибәсең дә берничә тапкыр сетканы әйләндереп аласың.

– Бәрәңгене җир температурасы ничә градуска кадәр җылынгач утыртырга кирәк?

– Туфрак температурасы 8 градуска кадәр җылынырга тиеш. Халык сынамышлары буенча, ул каен яфрагы тиен акча кадәр булганда.

– Кайберәүләр, бәрәңге эре булсын өчен, чәчәкләрен кисеп чыга икән...

– Миңа калса, бу нәтиҗәле чара түгел.

– Бәрәңгене көл белән кушып утыртучыларга ни диярсез?

– Туфракка калий кертергә кирәк. Агач көле исә калий чыганагы булып тора, шуңа өстәп, аңарда макро һәм микроэлементлар да бар. Моннан тыш көл, селтеле мохит тудырып, туфракның ачылыгын киметә. Бу исә үсемлеккә үсеп китәргә һәм авыруларга каршы торучанлыкны арттырырга ярдәм итә.

СОРАУ-ҖАВАП

Үзара салым түләүдән нинди категория кешеләр азат? Бу төркемгә сугыш елларында эшләүчеләр, 90 яшьтән өлкәнрәкләр һәм репрессия корбаннары керәме?

Гөлмирә.

Татарстан Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин аңлатуынча, үзара салым, аның күләме җирле референдум барышында билгеләнә. Референдум – үзара салымны законлаштыру дигән сүз. Моңа кадәр аны һәр җирлек советы төрлесе төрле вакытта үткәрә иде, әмма узган ел, әлеге эшне уңайлырак итү максатыннан, барлык районнардагы эшне бер көнне – ноябрь аенда башкардык. Исегезгә төшерәбез, халыктан җыелган һәр сумга дәүләттән дүрт сум акча өстәлә. Әлеге акча җирле мәсьәләләрне (зиратларны, һәйкәлләрне төзекләндерү, юлларга ком түшәү һәм башкалар) хәл итү өчен тотылырга тиеш.

Үзара салым турындагы закон нигезендә, референдумда аерым категория кешеләр өчен ташламалар да каралырга мөмкин. Үткән елларда, җирлек советы утырышы карары һәм референдум нәтиҗәләре нигезендә, үзара салым акчалары югары уку йортларында укучы студентлардан гына алынмады. Ә 2017 елда исә үзара салым түләүдән беренче группа инвалидлар, күп балалы гаиләләр (дүрт баладан күбрәк), ялгыз бала үстерүче әниләр, 85 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар һәм көндезге бүлектә укучы студентлар азат ителәчәк. Закон нигезендә, мондый ташламаларга ия кешеләр теге яки бу авыл җирлегендә яшәүче халыкның 30 процентыннан артып китмәскә тиеш. Әлеге категория кешеләр тулысы белән азат ителәме, әллә өлешчә генәме – монысы да референдум вакытында карала.

Шәхси хуҗалыкларда сыерларны ясалма орлыкландыру бушлаймы, түләүлеме?

Наилә,

Балтач районы.

«Элита» баш нәселле хуҗалыгы акционерлык җәмгыятенең баш зоотехнигы Фәнил Кәбиров әйтүенчә, әлеге хезмәт – түләүле. Бер сыерны каплату бәясе республика буенча – 1000 сум. Дөрес, дәүләт бюджетыннан 500 сум күләмендә субсидия дә каралган, әмма Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан әлегә аның системасын җайга саласы, документларын эшләп бетерәсе бар.

Инвалидлык бирү кагыйдәләре

sadsha.ru

Инвалидлык группасы алу кагыйдәләре үзгәргәч, редакциягә шактый сораулар килде. Укучыларыбыз сорауларына Татарстанның медицина-социаль экспертиза баш бюросы җитәкчесе Ригель Низамов җавап бирә.

Эльвира МОЗАФФАР

Инвалидлык алу тәртипләренә үзгәрешләр кертелде. Бу хакта тулырак аңлатсагыз иде.

Габделбәр ХӘЙРУЛЛИН,
Яшел Үзән районы.

– Россия Хезмәт министрлыгы тарафыннан расланган приказ нигезендә, 2014 ел ахырыннан инвалидлык алганда яңа күрсәткечләр кулланыла башлады. Яңа законнар буенча, инвалидлыкны билгеләгәндә, авыру кешенең функциональ мөмкинлекләрен ни дәрәҗәдә чикләгәнлегенә игътибар бирелә. Бу процентларда билгеләнә. Әлеге процентлар яңа приказда күрсәтелгән, аның белән һәркем таныша ала. Кыскасы, авыру нәтиҗәсендә кешегә күпме зыян килгәнлеге мөһим. Әйтик, кешене авыру функциональ яктан 0-30 процентка чикли икән, бу инвалидлык алу өчен җитди сәбәп дигән сүз түгел. Авыру китергән зыян 40-60 процент дип бәяләнә икән – димәк, инвалидлык икенче дәрәҗәдә дип исәпләнә. 70-80 процент булса – өченче дәрәҗә, 90-100 процент дүртенче дәрәҗә зыянны аңлата. Инвалидлыкны билгеләгәндә, сәламәтлеккә җитди зыян китергән функцияләрне кушып, процент дәрәҗәсен исәплиләр. Россия Хезмәт министрлыгының 2016 елның 6 февраленнән кабул ителгән карары нигезендә, инвалидлык критерийлары да исәпкә алына. Авыруның үз-үзен карый алуы, хәрәкәтләнүе, тернәкләндерүгә мохтаҗ булуына игътибар бирелә.

Бүген инвалидлык гомерлеккә биреләме?

Кәримә САФИУЛЛИНА,
Казан.

– Кабат тикшерү (переосвидетельствование) күрсәтелмәгән очракта, инвалидлык чикләнмәгән вакытка бирелә, ә 18 яше тулмаганнарга «инвалид бала» категориясе бирү каралган. Дөрес, инвалидлык билгеләнгәннән соң төзәтеп булмаслык морфологик үзгәрешләр, кимчелекләр, дәвалап булмаслык тайпылышлар, хроник лейкоз, яман шеш күзәтелгәндә, белгечләр тәкъдиме белән, инвалидлыкны чикләнмәгән вакытка бирәләр.

Инвалидлык алу өчен кая мөрәҗәгать итәргә?

Альбина САФИУЛЛИНА,
Казан.

– Инвалидлык алу тәртипләре Россия Федерациясе хөкүмәтенең «Кешене инвалид дип тану кагыйдәләре турында»гы 95нче карарында (2006 елдан) әйтелгән. Кагыйдәләр нигезендә, медицина оешмасы, диагностик тикшерүләр, анализлар нәтиҗәләре буенча, авыру кешене медицина-социаль экспертиза тикшерүе узарга җибәрә. Бередә сәламәтлеккә ни дәрәҗәдә зыян килгәнлеге ачыклана. Кешенең функциональ мөмкинлекләрен авыру ни дәрәҗәдә чикли икәнлегенә карап, инвалидлык төркеме билгеләнә. Әгәр дә медицина белгечләре юллама бирмәгәннәр икән, кеше үзе мөстәкыйль рәвештә медицина-социаль экспертиза бюросына мөрәҗәгать итә ала. Бу очракта анализ нәтиҗәләрен, табибның тикшерү узарга җибәрмәве турындагы язмача җавабын да үзең белән алып килү кирәк.

Элек инвалидлык алу күпкә җайлырак иде кебек. Хәзер бөтенләй башка кагыйдәләр. Группаны да ниндидер процентларга карап бирәләр икән, имеш. Бу үзгәрешләр нәрсәгә кирәк иде соң?

Асия САБИРОВА,
Апас.

– Киресенчә, хәзер документта организмның функцияләре бозылуның дәрәҗәләре һәм инвалидлык группасын билгели торган критерийлар тәгаенләнгән, бу үз чиратында ике төрле фикер тудыручы җөмләләргә төгәллек кертә. Инвалидлык алуда ришвәтчелеккә дә юл калдырмый. Чынлап та, яңа кагыйдәләр нигезендә, группа авыру сәламәтлеккә ни дәрәҗәдә зыян китергәненә карап билгеләнә. I төркем инвалидлык алу өчен, кешенең сәламәтлегенә 90-100 процент зыян килгән булу мөһим; инвалидлыкның II төркемен билгеләгәндә, функциональ мөмкинлекләр чикләнү 70-80 процент белән бәяләнә, сәламәтлеккә 40-60 процент зыян килгәндә, III төркем инвалидлык бирелә.

Еш кына аяксыз кешеләргә дә инвалидлыкны озайтырга туры килә. «Аяк үсеп чыкмый бит инде, нигә гел тикшерү узарга», – дип аптырый инвалидлар. Сез бу мәсьәләгә карата нинди фикердә?

Альбина ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,
Казан.

– Бары авыруны дәвалауга өмет калмаган очракта гына инвалидлык мәсьәләсе карала. Иң мөһиме – авыруны дәвалау. Төп максат – физик яктан мөмкинлеге чикле кеше үзен ташланган, онытылган итеп хис итәргә тиеш түгел. Пациентларны даими күзәтеп тору кирәк. Киселгән аяк, кул үсеп чыкмый, әлбәттә. Шулай да дәвалау юллары турында уйларга, техник тернәкләндерү чараларын дөрес сайлау мөһим. Мондый хәлдәге кешеләргә башта күнекмәләр өчен протезлар тәкъдим ителә. Әгәр кеше шушы җайланмалардан башка хәрәкәтләнә алмый икән, даими протезлар билгеләнә. Бу очракта инвалидлык группасы вакыты чикләнми.

Янгында танышымның инвалидлык турындагы белешмәсе югалды. Аны ничек кайтарырга?

Алисә СӘЙФЕТДИНОВА,
Балык Бистәсе.

Татарстанның медицина-социаль экспертиза баш бюросында белгеч табиб **Рәфидә Хәсәнова:**

– Теркәлү урыны буенча пенсия бүлегеннән тикшереп чыгу актының (акт освидетельствования) өземтә копиясен сорагыз. Ул белгечнең имзасы һәм печәт белән расланган булырга тиеш. Шул документ, паспорт һәм СНИЛСның копиясен алып, Казанга, Гафури урамы, 71нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстанның медицина-социаль экспертиза баш бюросына килә аласыз. Гариза тапшырганнан соң, бер ай эчендә архивлардан сезнең турында мәгълүматны эзләячәкләр, аннары инвалидлык турындагы белешмәнең дубликатын алырга мөмкин булачак.

Сәхифәбезнең киләсе темасы мәгариф өлкәсенә багышланачак. Баланы беренче сыйныфка бирү, мәктәптә уку-укыту программасына кагылышлы сораулар белән редакциягә **8(843)562-50-12, 562-50-03** телефоннары аша мөрәҗәгать итә аласыз.

Памперслар кайда?

Каенанама – 90 яшь. Ул – сугыш ветераны, I группа инвалид. Март, апрельгә памперслар ала алмыйбыз. Сатып ала башласаң, кыйммәткә чыга. 33 памперсның бәясе – 1200 сум, ул 15 көнгә җитә.

Рауза СӨНГАТУЛЛИНА,
Казан.

Инвалидларга игътибар җитәрлек булмауга күңелем әрни. Үзебезгә тиешлесен дә алып булмый. Мин ике инвалид карыйм, берсе – 90 яшьлек әнием, икенчесе – 56 яшьлек энем. 2016 елда 100дән артык памперсны китермәделәр. Сатып алырга туры килде. Ярый әле пеленкаларны таныш кешедән арзанрак бәягә алам. Бер инвалидка көненә бер пеленка, ике памперс каралган. Болар гына җитми, әлбәттә. Мин әнигә көненә 15әр пеленка тотам. Кадерле кешене гел юындырасы, чистада тотасы килә. Шөкер, күршеләрем гел ярдәм итә. Кайсы чүп түгәргә булыша, запас памперс белән бүлешүчеләр дә бар. 1 марттан тагын памперс китерми башладылар. Нигә инвалидларга шундый караш икән?

Мәрзия КУРМАНАЕВА,
Сарман районы, Җәлил бистәсе.

Әлеге сорауларга Татарстан буенча Социаль иминиятләштерү фондының төбәк бүлегендә социаль программалар бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары **Елена Гайнанова** аңлатма бирде.

– 2016 елның 1 гыйнварыннан инвалидларны протез-ортопедия эшләнмәләре, шифаханә һәм курортларга юлламалар һәм башка реабилитация чаралары белән тәэмин итү Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан Социаль иминиятләштерү фонды карамагына күчте. Әлеге күчеш процессы вакытында кайбер тоткарлыклар булды. Килешүләр төзү кичектерелде. Шуңа да памперслар белән тәэмин итилештә дә проблемалар килеп чыкты. Бу эш җайга салыныр дип ышанабыз. Бүген барлык инвалидларны да 28 февральгә кадәр памперслар белән тәэмин иттек. Ниһаять, 6-7 апрель көннәрендә икенче кварталга пеленка, памперслар белән тәэмин итү турында дәүләт контракты төзелде. Алга таба мондый тоткарлыклар булмас. Өченче кварталга да мәсьәлә инде хәл ителгән. Ә 2016 елда алынмаган памперсларга килгәндә, сатып алынган товар өчен чекларны китерсәләр, без акчаларны кире кайтарырга әзер.

Ата баласы хата булмас

ҮТЕП БАРЫШЛЫЙ

Равил САБЫР

«Сезне нәрсә шаккатыра ала?» Бер яшь журналист кыз миннән интервью алганда шундый сорау биргән иде. Чыннан да, яши-яши тиреләр калыная, күңел дә кырыслана, чөнки инде син күп нәрсәне күргәнсең, беләсең, тоясың – берни дә сиңа яңалык булып яңгырамас кебек. Шулай да ул чакта ике дә уйламыйча җавап кайтардым: «Кечкенә улым. Мин көн саен аңа шаккатам!» Хәер, бик үк төгәл әйтмәгәнмен фикеремне. Олы улым бәләкәй чакта аңа да шакката идем...

***

Рәзимгә (ул безнең беренче балабыз) биш яшьләр булгандыр. Әнисе белән сөйләшә бу.

– Әни, сез мине бакчадан кәбестә арасыннан таптыгыз бит, әйеме?

– Әйе, улым.

– Бабай мунча ягарга барганда минем кәбестә астында ятканны күргән дә өйгә алып кергән, әйеме?

– Әйе, улым.

Бала шул сүзгә риза булып елмаеп китеп барды. Күп тә үтмәде, әнисе янына йөгереп кергән.

– Әни, син нигә алдашасың?!

– Кайчан? Ни дип?

– Мине кәбестә астыннан таптык дип! Минем туган көн 23 февральдә, кыш көне бакчада кәбестә үсми!!!

***

Хатыным белән икәүләп кичен ниндидер бер иске, аклы-каралы сәвит фильмын карыйбыз. Өч-дүрт яшьлек Ришат почмакта «Лего» белән тыныч кына уйнап утыра, робот җыя. Кинода егет белән кыз танышалар, кичен клубта парлашып бииләр, аннары егет кызны өенә кадәр озата. Телефон чылтырады да, Римма икенче бүлмәгә чыгып кем беләндер тиз генә сөйләшеп алды һәм кире кино карарга керен утырды.

– Үбештеләрме соң инде? – ди.

– Соң бу бит 50нче елларда төшерелгән сәвит киносы! – дим. – Каян үбешсеннәр инде, үбешмәделәр! Советлар Союзында секс булмаган!

– Ә сезнеке булды, – дип куймасынмы Ришат!

Без Римма белән бер-берсебезгә карап каттык, ни әйтергә белмибез.

– Кайчан ул, улым? – дидем аптырагач.

– Ике тапкыр, – диде Ришат, хәйләкәр елмаеп һәм V хәрефе формасында безгә ике бармагын күрсәтеп. – Башта Рәзим абый туды, аннары мин.

– Соң, Ришат, без бит ни... Без бит сине кибеттән алып кайттык. Кыз алырга дип барган идек, акча җитмәде дә, сине сатып алдык, – ди әнисе.

– Мин сиңа тупоймыни, – диде дә Ришат, тырыша-тырыша, телләрен чыгара-чыгара, яңадан роботын җыярга керешге.

***

Олы улым Рәзимгә Тукайның «Шүрәле»сен укыйм.

Бик матур бер айлы кичтә
бу авылның бер Җегет
Киткән урманга утынга,
ялгызы бер ат җигеп.

«Әткәй, ә нигә ул урманга утынга төнлә бара, урлашыргамыни?» – ди Рәзим.

***

Кече улым Ришат белән (аңа җиде яшьләр тирәсе булгандыр) балалар кафесына барган идек. Әллә сораган һәрбер тәмле әйберен алып биргәнгә күңеле булды, гадәттә күп сөйләшми торган малайның кайтканда теле ачылып китте.

– Әткәй, миңа биш яшь булганда, мин озак уйладым: ни шәбрәк – тәмәкеме, кофемы? Аннары кофены сайлап алдым.

– Ә нигә кофены?

– Тәмәке тарту рәхәт түгел икән, аның төтене сасы, ул ютәлләттерә, бугазга рак чыгарга мөмкин, авызда әче тәм кала. Кофе да әче, кәнишне, тик аңа шикәр саласың да, ул тәмле була.

– Синең тәмәке тартып караганың бармыни?

– Әйе.

– Кайчан?

– Шул биш яшьтә инде.

– Каян алдың соң син аны?

– Синең кесәңнән, каян алыйм тагын?!

***

Рәзимнең 1нче сыйныфта укыган чагы иде бугай.

– Әткәй, синең эшең бетәме әле?

– Нигә?

– Миңа компьютер кирәк иде.

– Нәрсәгә?

– Пьеса язасым бар.

– Мә, алайса, утыр, яз.

Мин бер чәшке чәй эчкән арада, пьеса әзер иде инде.

«Яшәгән, ди, булган, ди, әби белән бабай. Боларның әтәчләре булган, ди. Ул, көн саен иртә таңнан кычкырып, боларны туйдырып бетергән. Шуңа бабай әтәчне суйган, ә әби аш пешергән».

Улымның пьесасын режиссер Булат Бәдриевкә күрсәттем.

– Әйбәт пьеса бу! – диде Булат. – Төп геройлар бар, конфликт бар, сюжет бар, чишелеш бар, сәхнәгә куеп була моны!

***

Ришатка өч яшьләр чамасы булгандыр. Өченче каттан аска җәяүләп төшәбез.

– Әйдә, улым, санарга өйрәнәбез, – дим.

– Әйдә.

Баскыч буйлап адым ясаган саен санап күрсәттем:

– Бер, ике, өч. Әйдә хәзер син шулай санап кара.

– Бер, ике, өч, – дип өч адым ясады Ришат шундук.

Беренче катка төшеп җиткәнче шул «бер, ике, өч»не кабатлап төштек, мин инде үземчә ныгып калсын дип тырышам. Ә беренче каттан подъезд ишегенә төшкәндә тагын бер кечкенә генә баскыч бар иде әле. Мин бер сүз дә әйтмәсәм дә, Ришат аннан да санап төшәргә булды.

– Бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде.

Исләрем китте, малай! Баксаң, ул инде әллә кайчан унга кадәр саный белә икән. Әнисе өйрәткән.

***

Рәзим кечкенә чакта ит ашамыйча интектерде. Тавык та ашамый иде, сыер итен дә, пилмәнне, дә, кәтлитне дә, пәрәмәчне дә, хәтта балык ашарга да яратмый иде. 90нчы еллар баласы ул, икътисади яктан шактый авыр заманалар. Алай да, Аллага шөкер, ач утырмадык, өстәлдә һәрвакыт сый-ризыклар булып торды. Үзебез дә тырыштык, әтиәниләр дә булышты, авылдан итнең төрледән-төрлесе килеп кенә тора иде.

Берсендә шулай медосмотрга алып бардык Рәзимне. Бик ябык иде ул, кабыргалары күренеп тора, рәхәтләнеп һәрберсен санап чыгарга була инде менә! Терапевт карады да моны, әйтә хатын белән икебезгә: «Аңлыйм, заманалар шактый авыр, тик шулай да балага атнага бер мәртәбә булса да итле аш пешерергә тырышыгыз инде зинһар», – ди. Шул чакта аңладым инде «җир тишеге булса, кереп китәр идем» дигән гыйбарәнең тулы мәгънәсен.

Тагын бер мәртәбә аңлатып күрсәтте әле аны миңа Рәзим! Анысы Минзәләдә. Бабай белән әбигә (хатынның әтисе белән әнисенә) кунакка кайткан идек. Җәйге чиллә вакыты. Ишегалдында Рәзим белән икәүләп шортыдан гына йөрибез. Күршедә яшәүче Рамил исемле егет килеп керде. Күләгәгә чүгәләп, тегесе-монысы турында сөйләшә башладык. Рәзим дә безнең кырыйда бөтерелә. Рамил минем корсакка, аннары баланың тырпаеп торган кабыргаларына карап-карап торды да:

– Бигрәк ябык син, Рәзим! Ит аша син күбрәк, әзрәк май кунар иде тәнеңә, – ди.

– Итне, пешеп чыгу белән, әти шундук ашап бетерә, безгә бер кисәк тә калдырмый! – диде дә Рәзим, йөгереп өйгә кереп китте.

***

Ришатка биш яшьләр чамасы. Әнисе балалар бакчасына алып килгән дә моны, өс киемнәрен салдыра башлаган. Болар янында тагын биш-алты бала чуала икән. Шунысын да искәртим, Ришат үзеннән бер яшькә зуррак балалар белән бер төркемгә йөрде, чөнки анда тәрбияче булып безнең бер танышыбыз эшли иде. Белгән кеше күз астында булгач, тынычрак бит инде барыбер.

Пәлтә-бүрекләрне салганнар болар, шул арада тәрбияче апа кулына куб алган да, аны баш өстенә күтәреп:

– Бу нәрсә? Кем дөрес җавап бирә, шуңа «бишле» куям, – дип әйтә ди.

Берсе дә җавап бирми икән.

– Улым, әйт инде, син бит беләсең ни икәнен, – дигән әнисе Ришатка.

Ул күз чите белән генә апасына күз ташлаган да:

– Куб, – дип, авыз эченнән мыгырдаган.

– Дөрес! Ришатка – «бишле»! – дигән апасы.

Аннары ул конус күтәргән:

– Ә монысы нәрсә?

Тагын берсе дә җавап бирми ди.

– Ришат, монысын да беләсең бит, әйт инде, – дигән тагын әнисе.

Ришат эндәшми ди. Кат-кат сорагач, үтенгәч кенә Ришат авыр сулап куйган да, ниһаять, әйткән:

– Конус. Ну, всё! Хәзер «алтылы» була инде...

***

Авылда әнидә кунакта чак. Рәзим йөгереп килде дә сорый:

– Әткәй! Аксөяк кем ул?

– Каян ишеттең әле ул сүзне?

– Ну, әйт инде?!

– Үзең әйт башта, каян ишеттең?

– Әбидән сораган идем: «Безнең көтү чираты җитәме әле?» – дип, ул әйтә: «Нигә ул сиңа, улым?» – ди. Мин әйттем: «Әти белән, Ришат белән көтү көтәргә чыгар идек, анда кызык бит!» – дидем. Ә әби әйтте: «Атаң көтү көтеп йөрмәс шул ул, аксөяк бит ул!» – диде. Әткәй, әйт инде, кем ул аксөяк?

ПОЧТАДАН

Җиләк җыйганда

Минем балачак истәлекләремнең күбесе хәзерге Әлки районы Татар Төгәлбае авылы белән бәйләнгән. 1947 елның июле иде. Корылык хөкем сөргән чак. Иген, бәрәңге уңмый. Халыкның яшәве авырлашкан еллар. Корылык булса да, кура җиләге, чикләвек күп булды ул елны. Мин дә яшьтәшем Мәсхүт белән каен тузыннан ясалган тырысларыбызны алып, авылдан ике чакрым ераклыктагы Төгәлбай урманына киттек. Чикләвек тә җыеп булмасмы дип, мәктәпкә йөри торган чүпрәк сумкаларыбызны да кыстырдык. Чикләвек сөт сыман, өлгереп кенә килә торган булып чыкты. Аның каравы рәхәтләнеп җиләк җыйдык. Тырысларыбызны тутырып, кайтыр юлга гына кузгалган идек, урман кырыеннан каршыбызга куркше авыл урман сакчысы Егор дәдәйнең әзмәвердәй ике улы килеп чыкты. «Урман сезнеке түгел, казнаныкы», – дип, җыйган җиләкләребезне талап алдылар. Инде нишлик? Буш кул белән өйгә кайтасы килми бит. Юлда арыш басуыннан башаклар җыярга булдык. Арыш башаклары балавыз сыман өлгереп килә. Чүпрәк сумкаларыбыз тулгач, авылга юл тоттык. Башакларны киптереп уып, кул тегермәненнән чыгартып, сөтле өйрә пешерергә була.

Авылдагы өч мәчетнең берсенең манарасы ничектер киселми калган иде. Аның биеклеге – 40 метр. Манара башыннан 6-7 чакрымдагы кырлар да күренә. Кыр сакчысы Габделбәр абый гел шунда менеп бинокльдән күзәтә иде.Үзе сугыштан яраланып кайткан. Кем нәрсә алып кайта, шуны тизрәк җитәкчелеккә хәбәр итә. Безне дә күреп алган бит бу. Манара ялтырап киткәне күземә чалынган иде. Шуңа да баласеннән баш аяк дип, мин башак тулы букчамны бакча буена бушатып калдырдым. Ул да түгел, авыл советы рәисе Зифа апа белән колхоз хисапчысы чатан Габделхәй абый да килеп җиттеләр. «Башаклар кайда?» – дип сорыйлар. «Без бит җиләк җыйдык, уып ашадык кына», – дип котылмакчы булам. Ә болар бөтен җирдән эзләргә тотынды. Сәке аслары, мич артлары калмады. Габделхәй абый, аягым авырта, дип тормады, идән астына кадәр төште. Чормадан, терлек абзарыннан да карадылар, таба алмадылар. Тапсалар, әтине бер айлык хезмәт хакыннан мәхрүм итәләр иде. Ни өчендер ул чакта авыл советы рәисе итеп читтән килгән коммунистларны билгелиләр иде. Алар аркасында, яман сүз әйткән өчен дә, кайберәүләр зинданга озатылды. Авылның эте дә авылга карап өрә, диләрме әле. Җитәкчелек үзебезнең авыл халкы арасыннан сайланган булса, ул дәрәҗәдә кырыс кыланмаслар да иде. Шөкер, бүген җитештә яшибез. Ул чактагы хәлләр генә истән чыкмый.

Сөләйман ШАКИРОВ,
Казан.

Базар кануннары

Чатырлы ярминкәләр ничек эшли?

Узган елның көзендә Казанда җиде урында чатырлы ярминкәләр эшли башлау турында язган идек инде. Әлеге сату нокталарын булдыру артыннан йөрүчеләрнең берсе – «Эко-фермер» авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы идарә рәисе Нурҗиһан Хәйретдинова безгә ул вакытта, сату нокталары фәкать фермерлар өчен генә тәгаенләнгән, алыпсатарларга анда урын булмаячак, дип, кат-кат басым ясап әйтте. Әмма Эшмәкәрлек буенча советның киңәйтелгән утырышында билгеле булганча, сәүдә нокталарын бүлү эшендә җитешсезлекләр бар, төгәлрәге, фермерларга дигелгән урында алыпсатарлар сата икән.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

ИСЕМДӘ БАР, САНДА ЮК?

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узган утырышта фермерларны борчыган шактый сораулар күтәрелде. Сөйләшү барышында авыллардан килгән фермерларның ярминкәдә көндезге сәгать уникегә кадәр генә сәүдә итә алуы да билгеле булды. Бу вакытка алар товарларын сатып бетерә алмый. Рөстәм Миңнеханов, кирәк булса, көндезге икегә-өчкә кадәр сатсыннар, фермер үз продукциясен күтәреп килә икән, без аңа урын табарга тиешбез, өстәмә сату мәйданчыклары булдырырга кирәк, дип белдерде. Татарстанның Фермерлар һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Камияр Байтемиров Президентка, берничә ярминкә белән ассоциация идарә итсен иде, дигән үтенечен җиткерде. «Эко-фермер» кооперативы идарә рәисе Нурҗиһан Хәйретдинова «ШК»га сөйләгәнчә, әлеге чатырлы ярминкәләрне булдыру артыннан фермерлар ассоциациясе ике ел йөргән.

– Аның инициаторы – без, әмма ярминкәләр белән идарә итү хокукын Казан Башкарма комитетына бирделәр. Өч мең фермер хуҗалыгын берләштергән ассоциациянең моңа хокукы юк. Без чатырлы ярминкәләрдә кече формалы хуҗалыклар һәм бакчачылар сатар дип уйлаган идек. Ә анда алыпсатарлар сәүдә итә. 15шәр мең сыеры булган агрофирмалар да шунда кереп кысыла. Әле аларның сату нокталары берничә ярминкәдә урнашкан. Гади авыл кешесе, фермер экологик яктан чиста, куркынычсыз продуктын сата алмый, ярминкәләргә үтеп керә алмый. Шуңа да Камияр Байтемиров Президенттан ике-өч ярминкәне фермерлар ассоциациясе кул астына бирүләрен сорарга мәҗбүр булды. Рөстәм Миңнеханов ике мәйданчыкны алырга рөхсәт итте. Нәрсә булып бетәр, әлегә бернинди яңалыклар да юк, – дип сөйләде ул безгә.

Аның сүзләренчә, ярминкәләрдә җитештерүче исеме астында сатучы ялган фермерлар – алыпсатарлар күп.

– Исемлеккә алар ничек килеп эләккән, нинди документлар нигезендә кергәннәр – билгесез. Сатарга теләгән фермерның җитештерүче икәнлегенраслый торган документлары – авыл җирлеге башлыгыннан шул җирлек кешесе икәнен, аның хуҗалыгы барлыгы турындагы белешмә кәгазе, паспортның ябыштыру урыны күрсәтелгән битенең күчермәсе, салым түләүченең шәхси номеры (ИНН) булырга тиеш. Фермер муниципаль берәмлекнең авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы исеменә гариза яза, ул министрлыкка юллана. Нишләптер исемлек атна саен үзгәреп тора. Менә бу һәм башка эшләр белән шөгыльләнә торган идарә компаниясе төзеләчәк, аның составына фермерлар ассоциациясе вәкилләре дә керә дип әйткәннәр иде. Ул идарәнең һаман төзелгәне юк. Ярминкәләр эшендә җитешсезлекләр күп, – ди Нурҗиһан Әгъзаметдиновна.

БАЗАР... ГӨРЛӘМИ

Шимбә көнне без дә берничә ярминкәдә булдык. 10нчы микрорайонда урнашкан чатырлы ярминкәдә без аралашкан Арча фермеры, монда сату итүче чын фермер мин генә, дип әйтеп куйды. Аның күршесендәге эремчек, сыр, май сатучыдан, үзегезнең продуктларны, дип сорыйм. Әйе, ди. Сырга «Арча-Вамин» дип язылган, мае Балтачныкы булып чыкты. Сезнең товар кайда соң, дигәч, пакетка тутырылган эремчекләрне күрсәтте. Алары үзенекеме-юкмы, гомумән, ул чынлап та фермермы – белгән кеше юк.

Эшмәкәрлек буенча совет утырышында фермерларның иртүк килеп урын алуы турында да сүз булды. Батыршин урамындагы ярминкәгә төнлә үк килеп басалар икән. Шул сату мәйданында сәүдә итүче – Кайбыч районыннан килгән фермер (исемен әйтергә теләмәде), төнлә килеп, машинада кунабыз, югыйсә урынсыз каласың, дип сөйләде. Сез исемлектә юкмыни, дигән сорауга, бар, исемлек зур бит, бөтен кешегә дә урын калмый, дип җавап бирде. Ә менә Зәкиев урамындагы ярминкәдә сату итүчеләр бик аз, юк диярлек. Көздән бирле ул ни фермерлар, ни сатып алучылар арасында популяр түгел. Без анда да булдык. Буа егетләренең бирегә өченче атна килүләре икән, итләре начар сатыла. Алар янәшәсендә сату иткән Чистайдан килгән ханым биредә беренче генә тапкыр икән. Аның Казанга гомумән килгәне булмаган, Түбән Камада гына сату иткән.

– Монда сатып алучы бөтенләй юк икән, әллә йокларга яраталармы шунда, аптырап басып торам, – диде ул.

Сатарга урын булмаудан зарланучыларны бирегә китереп саттырып кына булмыймы икәнни?.. Әлеге сорауны мин 10нчы микрорайонда сату итүчеләргә бирдем.

– Ишетеп белүебезчә, анда халык йөрми. Безгә бит сатарга кирәк, – диделәр алар.

12ДӘН СОҢ – ТҮЛӘҮЛЕ

Сату дигәннән, фермерлар товарларын сәгать уникегә кадәр генә сатуын, аннан соңгы вакытка калсаң, акча түләргә кирәк булуын да әйтте.

– Сәгать нәкъ уникe булгач, касса аппаратларын тотып килеп җитәләр. Бер мең алалар, бүген юньләп сатып булмады дигәч, 500 сум бир, дип сорыйлар, – ди алар.

– Кемгә һәм ни өчен бирәсез?

– Район администрациясе бугай инде, җыештырган өчендер, анысын үзләре дә әйтми, без дә артык сорау бирмибез. Үз артыбыздан җыештырабыз анысы... Без бит уникегә кадәр генә сатарга тиеш, бу урыннарны базар хуҗаларыннан безнең өчен шул вакытка кадәр генә сорап алганнар, ә төштән соң эшмәкәрләр сатарга тиештер, – дип фаразлый алар.

Боларны безгә Батыршин урамындагы, Лаврентьев урамындагы һәм 10нчы микрорайондагы ярминкәдә сату итүчеләр сөйләде.

– Рөхсәт бирсәләр, икегә, дүрткә кадәр дә сатар идек, әллә ничә чакрым ераклыктан килеп, товарны сатып бетереп кайтасы килә бит, – диләр.

Чатырлы ярминкәләр Фучик урамындагы 64нче йорт, Липатов урамындагы 7нче йорт, Зәкиев урамындагы 12нче йорт, Дементьев урамындагы 7нче йорт, Беломорск һәм Гудованцев урамнары киселешендәге 34нче йорт, Батыршин урамындагы 20нче йорт һәм Лаврентьев урамындагы 10нчы йорт янында урнашкан.

Нурҗиһан Хәйретдиновага без бу хакта җиткердек. Акча җыю турында ул ишетеп белә икән.

– Мин бу проблеманы беләм. Үземә дә фермерларның шалтыратканнары булды. Акча җыю турында бер генә карар да, документ та юк. Сату вакыты чикле булу да бездән тормый. Аны Авыл хуҗалыгы министрлыгы хәл итте. Мескен фермер төнлә торып, юлга чыга. Итен алып килеп сатуга киштәгә куйганчы, күпме акча чыгара ул. Үзегез дә беләсез, терлекне сую шартлары буенча таләпләр катгыйланды. Алты сәгать эчендә сатып бетерелергә тиеш. Әле кайбер базарларда халык иртән йөрми дә, тугыз-унда гына чыга. Фермерның сату өчен нибары ике-өч сәгать вакыты бар. Килгән килгән, сатып бетереп сөенеп кайтып китсен иде инде ул. Бу мәсьәләне чишәрләр дип өметләнәбез. Президент авыл хуҗалыгы министры урынбасары Николай Титовка сату вакытын көндезге икегә-өчкә кадәр озайтырга кушты, – дип сөйләде ул.

ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘР КИРӘК ТҮГЕЛ?

«Добро мясо» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять директоры Рамил Галиевнең ярминкәләргә үз үпкәсе бар. Өч елдан артык инде ул казылыклар җитештерә. Товарын Авиатөзелеш районындагы ярминкәдә автолавкада сата. Тагын бер автолавка алып, Батыршин урамындагы ярминкәгә керергә уйлаган.

– Мине анда кертмәделәр, намуслы җитештерүчегә рәхәтләнеп эшләргә ирек бирмиләр. Гомумән, җитештерүчеләр Татарстанга кирәк түгел, дигән нәтиҗәгә килдем. Аның каравы, каяндыр күпләп сатып алып, кыйбатрак бәягә казылык белән сәүдә итүче алыпсатарлар белән базар тулган. Ә мин үзем җитештергән сыйфатлы ризыкны үзебезнең халыкка чыгарасым килә, – ди ул.

Ничек кенә булмасын, ярминкәләр шәһәр халкына кирәк, иртәнге алтынчы ярты булуга карамастан, Нәҗия апа белән аның күршесе Миңзифа әбинең базарга икенче кат чыгып керүләре иде.

– Авыл эремчеге, маен, чәйгә салып эчәргә сөтен дә алдык. Сыйфатлы ризык ашыйсы килә бит. Авылдан килгән сөт ризыклары арзанрак та, тәмле дә, файдалы да була, – дип куанып китеп бардылар алар минем янымнан.

Эремчек дигәннәре «эремчек продукты» гына була күрмәсен инде. Ярминкәдә андый эремчекне дә саталар бит.

«ШӘҺРИ КАЗАН»нан – алма бакчасы

Бу язылу кампаниясендә укучыларыбызны нинди бүләк белән сөендерик икән, дип озак уйландык. Үзе файдалы да, истәлекле дә, матур да булсын иде ул бүләк. Уйлый торгач таптык тагын: без сезгә, Югары Ослан районының Ямбулат авылындагы «Заря» питомнигы белән берлектә, алмагач үсентеләре бүләк итәбез!

Бүләк алуның әллә ни кыенлыгы юк. Газетадагы анкетаны тутырып, 2017 елның II яртыеллыгына язылу турындагы квитанцияне редакциягә җибәрергә һәм җирәбә нәтиҗәләрен генә көтәргә кирәк. Үзегезгә ничек җайлы, шулай эшләгез, без аларны почта аша да, электрон адресыбызга да, «ватсап» аша да, социаль челтәрләрдәге төркемнәребездә дә кабул итәбез. Бүләк ике атна саен уйнатылачак, беренче үсентеләрнең хуҗаларын инде 26 апрельдә үк ачыклаячакбыз. Җирәбә уйнатуны видеога төшереп, www.shahrikazan.com сайтында урнаштырачакбыз.

Әйдәгез, алма бакчасында «Шәһри Казан» укыйк әле!

ИНДЕКСЛАР
П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **401 сум 94 тиен.**
П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **816 сум 90 тиен.**

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон______________________

2. Яшегез______________________

3. Шөгылегез______________________

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?______________________

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?______________________

6. Газетага ничек языласыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?______________________

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?______________________

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?______________________

10. Газетаның миңа иң ошаган:______________________

ошамаган яклары:______________________

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?______________________

Языл
«Шәһри Казан» газетасына почта бүлекчәләрендә яки интернет аша языл

→ **Анкетаны тутыр** →

Җибәр
Анкета, квитанцияләр, «Алмагач» дигән тамга белән, түбәндәге адресларга кабул ителә:
Почта аша: 420066, Казан, Чистай урамы, 5нче йорт, «Шәһри Казан» редакциясе
Электрон почта: shahri-kazan@tatmedia.com
Ватсап: 8 917-851-69-62
Социаль челтәрләрдәге төркемнәр:
vk.com/shahrikazanda
facebook.com/shahrikazan
ok.ru/shrikazan

Газетага ничек язылырга?

1. ТАТАРСТАННЫҢ ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ПОЧТА БҮЛЕГЕНДӘ

2. Казан шәһәрендә өегезгә дә килеп яздырабыз. Моның өчен **562-50-12** яки **8-917-851 69 62** номерларына шалтыратып, заявка калдырырга кирәк

3. ИНТЕРНЕТ АША – ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ПОРТАЛЫНДА

Моның өчен кул астында интернетка тоташкан берәр җайланма булуы гына кирәк
1. uslugi.tatarstan.ru сайтына кер;
2. «Подписка: газеты и журналы» дигән төймәгә бас;
3. Шәхси кабинетыңа кер;
4. «Шәһри Казан» (электрон каталогта – «Шахри Казан») газетасын сайла;
5. Адресыңны яз;
6. Дәүләт хезмәтләре порталы аша квитанцияне түлә.

Реклама

Тулырак мәгълүмат shahrikazan.com сайтында

МАТУРЛЫК САЛОНЫ

Кастор мае керфекне үстерә

✓ Чәчегез ялтырап торсын, сәламәт күренсен өчен, атнага бер тапкыр кастор мае сылагыз.

✓ Чәчләр өчен тагын бер маска: бер чынаяк кефирны кайнар сулы тәлинкәдә тотып җылытыгыз да аңа биш тамчы кастор мае тамызыгыз. Катнашманы чәчегезгә сылагыз да полиэтилен шапка киеп, өстеннән сөлге урагыз. Ярты сәгатьтән соң чәчегезне юыгыз.

✓ Чәч коелганнан: бер өлеш майга ике өлеш аракы кушып, шуны чәч төбенә сылагыз.

✓ Кавыктан котылу өчен: бер стакан кайнар кара чәйгә бер чәй кашыгы кастор мае һәм 20 грамм аракы салып болгатыгыз да аннары чәчегезгә сылагыз. Бер сәгатьтән соң юыгыз.

✓ Кастор мае керфекләрне дә үстерә. Атнага берничә тапкыр төнгә каршы керфегегезгә сылагыз. Кастор маена балык маен да кушарга була (1:1).

✓ Кастор мае коры битләр өчен дә файдалы. Бер күкәй сарысына ун тамчы кастор мае кушып, битегезгә сылагыз һәм унбиш минуттан соң юып төшерегез. Соңыннан битегезне яшел чәй белән юсагыз, тагын да яхшы.

КИҢӘШ САНДЫГЫ

АЛТЫН КИҢӘШЛӘР

Шәхес буларак үсәргә безгә нәрсә комачаулый?

СОҢГА КАЛУ

Сез артык уйлыйсыз кебек түгелме? Тотарга да эшлисе урынга «Ә нәрсә була, әгәр...», «Ә кинәт...», «Барып чыкмаса...» кебек сораулар биреп, үзегезне җәфалап бетерәсез. Бер адым ясар өчен барысын да исәпләгән, фаразлаган буласыз. Ерак киләчәккә исәпләнгән планнар – кирәкмәгән ялган өметләр. Нишләп әле бөтен куркуларны «селтәп ыргытып», тормыш белән кул кысышып килешмәскә? Тормыш ул куйган максатыңа бару һәм ирешү өчен иң гади, кыска юлны үзе белә.

ГАЕПЛӘҮ

Уңышсызлыкларыңда башка кешеләрне гаепләү. Үз дигәнеңә ирешә алмаганнар йөзләгән сәбәп табарга мөмкин, ә гаепне үзеннән эзләми ул. Бу – җаваплылык хисе булмаудан. Үзеңне уңышсызлыкның корбаны дип санама, ә тормышның хуҗасы булырга өйрән. Беркемне гаепләргә дә, беркем алдында акланырга да кирәкмәячәк.

АКЛАНУ

Әгәр дә кеше аклана икән, ул үзен гаепле сизә дигән сүз. Аклану гаепләү белән тыгыз бәйләнгән, шәхес буларак үсештә өченче каршылык булып тора.

Һәр көн алга – максатыгызга, хыялыгызга таба барырга тырышыгыз, беркайчан да тукталмагыз.

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА

ДЖЕННИФЕР ЛОПЕСтан «Җылы сөт» диетасы

Әлеге диета ярдәмендә ул бер атна эчендә биш килограммга ябыккан, дип яза starhit.ru. Актриса һәм җырчы организмнан артык сыеклыкны җылы сөт ярдәмендә чыгара. 2 процент майлылыгы булган 800 мл сөтне ул 70 градуска кадәр җылыта һәм көн дәвамында ике сәгать саен 100әр гр эчә. Аннары гәүдәнең аскы өлешен җылы сөлге белән урап куеп, 10-15 минут буена аягын күтәреп ятып тора.

ДИЕТАНЫҢ ЯКЫНЧА РАЦИОНЫ

Иртән: бер күкәй, 20 граммлы ике кисәк ипи.

Төшке аш: 150 гр бәрәңге боламыгы яки бер пешкән бәрәңге.

Кичке әбәт: 5-6 данә күрәгә яки кара җимеш.

Кичке аш: 200 гр тавык түше.

ХУҖАБИКӘГӘ

Бәрәңге боламыгын тәмле итү серләре

- Бәрәңгене изгәннән соң, аңа каймакка уылган сыр һәм вак итеп туралган сарымсаклы катнашма салыгыз да аз гына газ мичендә тотып алыгыз.
- Бәрәңгегә сөт урынына кайнар тавык шулпасын салып изүчеләр дә бар.
- Сөт урынына берничә кашык каймакка бер-ике күкәй сытып болгатыгыз.
- Бәрәңге боламыгына аз гына сыер мае һәм вак итеп туралган укроп, петрушка, яшел суган, сарымсак салыгыз.
- Боламыкка вак итеп туралган чикләвек салу да аның тәмен үзенчәлекле итә.
- Боламыкка дигән сөт кайнар булырга тиеш. Салкын сөттән ул соры төскә керә. Бәрәңге боламыгы озак итеп тугаганны ярата.

АШ БУЛСЫН

«Эдельвейс» салаты

2 помидор, 1 кыяр, 1 банка консервланган кукуруз, 150 гр пешкән тавык түше, 1 баллы борыч, яшел суган, сохари, сарымсак, тоз, борыч, үсемлек мае (зәйтүн мае да ярый)

Яшелчәләрне һәм тавык итен бик вак итми генә турыйбыз. Сохари урынына батонны шакмаклап турап кыздырып алсаң да була. Сарымсакны вак итеп турыйбыз. Барысын бергә кушып, катнашмага кукурузны салабыз, тоз, борыч сибәбез, май агызабыз да болгатабыз.

ГӨЛЛӘР ПОЧМАГЫ

Гөлләр тиз тамыр җибәрсен өчен, әлеге ысулны кулланып карагыз. Моның өчен пенопласт, бер төймә активлаштырылган күмер, бер стакан су һәм гөл ботагы кирәк. Бу ысулны кулланганда гөл ботагы гел билгеле бер тирәнлектә тора, ә күмер черергә ирек бирми.

Әйбәт уңыш алу өчен җимеш агачларын, әйтик, алмагачның ябалдашын кисеп торырга кирәк. Язын аларны беренче бөреләре чыгар алдыннан кисәләр. Моның өчен фәкать яхшы итеп үткенләнгән секатор (яшь ботаклар өчен) һәм пычкы (карт ботаклар өчен) кулланыла. Алар кугәргән булырга тиеш түгел. Алмагачның яшенә карамастан, коры, өшегән, сәламәт булмаган ботакларын кисеп торыгыз. Ябалдашларны дөрес формалаштыру схемасы рәсемдә бирелгән.



БАКЧАЧЫГА

- Апрель-май айларына бакчачыларга җимеш агачларын корткычлардан һәм авырулардан саклау эшенә керешергә кирәк.
- Узган елны агач-куакларның авыру яфраклары һәм җимешләре күп булган булса, бөреләре чыкканчы, һава температурасы +4тән узганда, 3 процентлы бордо сыекчасы белән эшкәртегез. Эремәне «бордо сыекчасы» дип аталган порошоктан әзерләгез.
- Үткән елны агач-куакларның яфраклары кипкән яки кугәрек таплар белән капланган булса, Хорус препараты белән эшкәртегез. Вак корткычлар да һөҗүм иткән булса, әлеге препаратка Актара, Децис профи, Фуфанон-Нова кушыгыз.
- Агач-куакларның ботаклары һәм җимешләренә корткычлар ияләшкән булса, Децис профи, Фуфанон-Нова, Алатар, Кинмикс препаратлары сиптерегез.
- Алмагач белән груша яфрагында шикле таплар барлыкка килсә, Скор яки Раек, Строби белән эшкәртегез. Бу вакытка бакчага корткычлар да һөҗүм итсә, урамда +18гә кадәрге температура торса, эремәгә Фуфанон-Нова яки Искра М, яисә Кинмикс та кушыгыз. Көн эссерәк булганда, әлеге катнашма урынына Лепидоцид, Битокси-бациллин яки Фитоверм кулланыгыз.
- Үткән елны сливагызның яфраклары тишкәләнеп беткән булса, Хорус препараты белән эшкәртегез.
- Үткән елны груша белән алмагачыгызда кутыр (парша) кебек гөмбәле авыру күзәтелгән булса, аларга Скор, Раек, Строби сиптерегез.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

Телевизор диагонале размерын ничек сайларга?

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ



12 апрель – Космонавтика көне

Галәмдә – татар уллары

Галәм техникасы телен белүчеләр арасында безнең татар уллары да бар. Бүгенге әңгәмәбез шуларның берсе – 60 елга якын гомерен авиация һәм галәмгә багышлаган инженер-сынаучы Рәсим Җәүдәт улы Бикалов белән.



– Рәсим әфәнде, 1961 елның 12 апрелендә бөтен дөньяга яңгыраган «Кеше – галәмдә!» дигән хәбәрне сез кайда ишеттегез?

– Апрельнең бу истәлекле көнендә мин КАИның самолетлар төзү факультетының 4нче курсында лекция тыңлый идем. Очу аппаратларының очыш динамикасы дигән яңа белгечлек буенча. Ул чакта берничә елдан атаклы Королев конструкторлык бюросында (хәзер Сергей Королев исемендәге «Энергия» Ракета космос корпорациясе) Мәскәү өлкәсе, Королев шәһәрендә эшләрмен дип башыма да килмәде.

– Менә сезнең кулыгызда инженер дипломы. Хезмәт юлыгызны кайда башладыгыз?

– Яшь белгеч булып Мәскәү өлкәсе, Дубна шәһәрендә конструктор Березнякның бюросында эшли башладым. Ул БИ-1 самолетларының конструкторы иде. Ракеталар аэродинамикасы бүлегендә исәпләүләр үткәрдем. Ләкин күңелем сынау эшләренә тартылды. 1967 елны мине Королев конструкторлык бюросына сынау комплексына алдылар. Атаклы конструктор үзе исән түгел иде инде. Ләкин ул башлаган эшне күп кенә хезмәттәшләре лаеклы дәвам итте. Бу чорда галәмне чын-чынлап штурмлау башланган иде.

– Сезнең тормыш тоташ маҗарадан, сәяхәтләрдән тора инде алайса.

– Әйе, СССР космонавтикасы тарихы – ул минем дә хезмәт юлымның тарихы. Ай программасы буенча ракета-космос сынауларында катнаштым. «Союз», «Прогресс» беренче орбиталь транспорт кораблары, беренче орбиталь станция «Салют»ның исәпләүләрендә булдым. Баштарак гел Кырымга командировкага бара идек. Анда Евпатория янында 1нче ЦУП (очышлар буенча идарә итү үзәге) бар иде. Байконурда, Ерак Көнчыгышта космик корабларның очышларын күзәтергә туры килде. «Космонавт Владимир Комаров»та – җиде, «Космонавт Юрий Гагарин»да – дүрт һәм «Академик Сергей Королев» теплоходларында ике тапкыр диңгез-океан экспедицияләрендә катнашырга туры килде. Атлантик океанда, Урта диңгездә очышлар программасы эшендә катнашып, космик кораблар очышын күзәтеп тордык. Әйе, галәмгә җирдән керфек тә какмый карап торалар. Шул чакта 12 илдә булып, Европа, Азия, Төньяк һәм Көньяк Американың 20лап шәһәрендә булдым. Куба һәм Антиль утрауларының онытылмас тропик табигатен күреп тә сокландым. Хәзер сугыш бара торган Сүриянең Латакиенда булдым. Аннары «Мир» орбиталь станция һәм Халыкара космик станцияләрнең очышын тәэмин итүдә эшләдем, бүген дә шунда эшлим. Җентекләп сөйли алмыйм. Анысы – дәүләт сере. Быелның 27 июлендә космос хезмәт итүемә, шул системада эшли башлавыма 50 ел була.

– Галәм, кунакчыл хуҗа шикелле, ишекләрен киң ачып, кешеләрне көтеп тормый шул. Фаҗигаләр хакында да ишетергә туры килә.

– Әйе, уңышлы очышлар күп булган кебек, фаҗига белән тәмамланганнары да булгалады космонавтика тарихында. Бик кызганыч, әлбәттә. Алардан без сабак алабыз. Ләкин зур югалтулар бәрабәренә.

– Галәм серләрен ачуга безнең татарлар да күп өлеш керткән, хәтта беренче космонавтлар отрядында да татарлар булган.

– Әйе, безнең халык – тырыш, максатчан. Без бит сугыш чоры балалары. Иртә җитлеккән, аерым бер каты токым. Сынаулар алдында сынмадык, сыгылмадык. Тырышып укыдык. Менә мин үзем – Төрекмәнстанның Чарджоу шәһәрендә туган татар малае. Әтием – Татарстанның Буа районы Яңа Тинчәле авылының атаклы мулла нәселеннән. Бабам Касыйм Бикколов татар әдәбиятында беренче тарихи роман язган әдип буларак билгеле. Китаплары чит илдә, хәтта Япониядә дә басылган. Узган ел «Шәхесләребез» сериясендә нәселебезнең ике асыл улы турында китап та нәшер ителде. Аны дөньяга чыгаруда ярдәм күрсәткән һәркемгә олы рәхмәтемне җиткерәм. Әлеге китап бүген дә безнең халыкның гыйлемгә тартылуын, дус-ярдәмчел булуын күрсәтә торган мисал. Космос өлкәсендә милләттәшләрем шактый. Королевның хезмәттәше – атаклы белгеч Рифат Аппазов, инженер-сынаучы, очу белән идарә итүче Әкрәм Конеев һәм башкалар. Әлеге исемлекне, бәлки, бүген парта артында утыручы нәни милләттәшләрем дәвам итәр. Галәмгә юл Җирдән башлана ич.

– СССР космик держава дип күкрәк кага иде, хәзер Россия болай дип горурлана аламы?

– Үзгәртеп кору елларында илебезнең машина төзү һәм космос сәнәгате шактый кыенлыклар кичерде. Чөнки космос – бик күп чыгымнар сорый торган өлкә. Бигрәк тә галәмгә космонавтлар җибәрү алгаем зур суммага төшә. Ләкин яңа заманда галәмне тикшерүнең әһәмиятен аңлый башлап, бу кирәкле эшкә акчаны кызганмаска өйрәнеп килгәнгә, әкренләп яңа шартларга җайлашабыз, авырлыклар чигенә. Безнең эшне дәвам итәргә белемле яшьләр дә килә. Шунысы да сөендерә.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

ТОРМЫШ КЫЙПЫЛЧЫКЛАРЫ

Еларгамы?

Төрле хәлләр була инде тормыш казанында кайнаганда. Тырышабыз,тырмашабыз, шаярып-көлеп тә алабыз, күз яшьләренә бөялгән чаклар да була. Өзелеп елыйсы килә шул кайчак. Чарасызлыктанмы, үзеңнекен аңлата алмаганлыктанмы? Күз яшьләре ул җәлләүдән генә, диләр. Башкалардан кызгандырмыйча, сиздерми генә елап алсаң, бәлки, гөнаһ түгелдер.

Ул көн җайлы гына башланды. Эшенә килеп җитүгә, барысы да гадәттәгечә иде. Кәгазь, папкаларны тәртипкә китереп куйгач, иплән кенә компьютерны кабызып җибәрде, күнегелгән эшенә тотынды Ләйлә. Ул – сәркатиб, җитәкчесе әле килеп җитмәгән, аңа кадәр кирәкле хәбәрләрне барлап куясы. Шул вакыт күрше бүлектән, өермәдәй, Наташа килеп керде:

– Үткән кварталның отчеты кирәк иде, бөтенләе белән түгел, менә бу, менә бу һәм шушы урыннары, – дип кырт борылып, биек үкчәләрендә шырт-шырт басып, чәчен җилфердәтеп чыгып китте.

Аның үтенечен барлаганда, кыенсынып кына, олы яшьтәге абый килеп керде.

– Сезгә җибәрделәр, ни өчендер хезмәт хакын дөрес чутламаганнар, – диде ул, ишек кырыеннан үтмичә.

Цехта эшләүче Гамил абый икән. Олы кешене тоткарлап булмый бит инде, компьютерда кирәкле бүлекчәне ачып, абыйның гозерен үтәргә керешә. Тырыша торгач ачыкланды: алдагы айда эштәге юллама буенча шифаханәдә ял иткән икән. Шул юллама бәясенең җиде процентын басып калганнар.

Ул чыгып китүгә, телефон чылтырады.

– Мәгълүматлар кабул итегез, приказга кертегез.

Тагы чылтырады.

– Телефонограмма, кабул итегез.

Ишекне киң ачып, Наташа күренде

– Миңа кирәк, бик тиз!

Шуннан соң ишек ябылмады да диярлек. Һәрберсенә ни дә булса кирәк һәм бик тиз. Өлгереп кенә җит. Бүлмә кырмыска оясыдай мәш килде. Кайсысыдыр папкаларга ялгыш кагылып алды, кәгазьләр идәнгә чәчелде. Җыеп бетердем дигәндә, күтәрелгән чакта башының арт чүмечен өстәл почмагына бәреп, күзләрен чытырдатып йомды. Иреннәрен кысып, керфекләрен ачканда, карашы елтыр ботинкаларга төште. «Хуҗа» килгән.

– Тәртипме?

– Әйе, – диде Ләйлә, тураеп.

– Ярты сәгатьтән китәм, мөһим кәгазьләр булса, тапшырыгыз.

Җиң сызганып эшкә чумды. Сизелми генә төшке аш вакыты җиткән. Бүлмә бермәл тынып калды. Соңлап булса да күрше бинадагы ашханәгә барып килим дип чыкса, юлны кызыл тасмалар белән аркылы чикләп куйганнар, түбәдә ремонт эшләре бара. Кире борылып кереп, чынаяк тутырып салкын су эчкәндә, мышкылдап куйды. Еламаска иде дип, эшенә керешә. Көннең икенче яртысы иртәнгесеннән дә «кайнаррак» булды. Кичкә таба башы умарта күчедәй гүли иде.

– Бу урында хата җибәргәнсез, төзәтегез.

– Приказга үзгәрешләр керттегезме?

Бераз җае чыкса, елап аласы килде. Тик һаман:

– Белешмәләрне җиткерегез!

– Мәгълүматлар белән соңламагыз!

Эш сәгате беткәндә, күңеле мөдәрәмә тулган иде. «Хәзер өйгә кайтам да елыйм». Шунда көн дә эшеннән машина белән каршы алучы тормыш иптәшенең әнисе йомышлары белән мәшгуль булуы беленде. Күзләрендә тукталып калган яшьләрне йотып юлга чыкты. Хәзер тукталышка барасы, җәмәгать транспортына утырасы, еларга ярамый әле. Эчендә кайнаган дулкынны басарга тырышып, еш-еш сулап, троллейбуска узды. Халык шыплап тулган, утыру түгел, ишек кырыннан көчкә урын табылды. Кешеләр аны, теләмәсәләр дә, эткәләде-төрткәләделәр. Бер сәгатьләп шушы мәхшәрдә кайткач, кирәкле тукталышта чыгып, иркен сулыш алды. Үз йортларына чаклы ярты сәгатьләп җәяү күтәреләсе. Карлы-бозлы, кара туфраклы караңгы көзге кич. Ачы салкын җил үзәккә үтә. Түмгәкләр аша, сөрлегә-каплана, алга атлады. «Хәзер елыйм». Тик күзеннән сыңар яшь тә чыкмады. «Минме?» – «Елыйммы?» – «Булмаганны!» – «Көн түзәрлек булды әле». Каршы җилгә йөзен куеп туры атлады. Адым саен рухы ныгыды.

Лүзия САЛИХОВА,
Казан.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

ОЧЫШТА

Казан вертолет заводында бер көн

Дөньяда иң киң кулланыла торган «Ми-8» вертолетлары Казан вертолет заводында җыела. Очкычларны күргәнебез булса да, алар турында күп ишетсәк тә, ничек җыелганлыгын күпләр белми. «ШК» журналистларына исә бу серне чишәргә ризалаштылар. Бер көнебезне очкычларны җыю цехында уздырдык.

Эльвира МОЗАФФАР

ЗАВОД ҮЗЕ БЕР ДӨНЬЯ

77 еллык тарихы булган Казан вертолет заводы – Татарстандагы иң заманча предприятиеләрнең берсе. Бүген ул «Россия вертолетлары» холдингына керә, «Ми8/17» вертолетларын проектлау сериясле конструкторлар бюросы булган һәм инновацион эшләнмәләр белән мөстәкыйль шөгыльләнгән бердәнбер предприятие санала. Шуңа да монда әлегә дә җиңел түгел. Җитәкчелектән рөхсәт алганнан соң да, заводка кергәндә мең кат тикшерәләр. Вертолетлар җыю цехына юл завод бакчасы аша уза. Территориягә килеп керүгә, музей бинасы күзгә чалына. Биредә заводның тарихы чагылдырылган экспонатлар урын алган. Хәер, завод бакчасындагы вертолет макетларын күреп, урамда да ачык һавадагы музей дияргә була.

Әнә легендар «ПО-2» – бомбага тотучы самолет. Аны халык теләндә «Төнге үлем» дип тә йөрткәннәр. Бу очкычлар нәкъ менә төнлә очкан. Билгеле бер тизлек алганнан соң, сүнгән двигатель белән дә дошманга һөҗүм итәргә сәләтле булган. Тарихтан билгеле булганча, немецлар бу очкычлардан уттан курыккан кебек курыкканнар. 1941 елдан 1948 елга кадәр Казан вертолет заводында барлыгы шундый 11 334 очкыч җыелган.

«Ми-1» – конструктор Михаил Миль эшләп чыгарган беренче совет вертолеты. Хәзер «Ми» сериясендәге вертолетлар («Ми-4», «Ми-8», «Ми-14», «Ми-17», «Ми 8/17») бөтен дөньяга билгеле. Тиздән «Ми-8/17» вертолетының дәвамчысы – комплектацияләре яңартылган «Ми-38» табадан төшәргә тора. Әлеге вертолет 4 тонна йөк күтәрә, 28ләп пассажирны сыйдыра ала икән. Шулай ук аны эзләнү-коткару эшләрендә дә кулланырга уйлыйлар.

Медицина өлкәсендә, янгын сүндерүдә файдаланыла торган «Ансат» очкычлары тулысынча Казан вертолет заводында җыела. Моның белән шөгыльләнүче аерым тәҗрибә конструктор бюросы да бар. Күп максатта файдаланыла торган җиңел «Ансат» вертолеты кирәкле медицина модуле белән җиһазландырылган, ул эре мегаполисларда «оча торган ашыгыч ярдәм» хезмәте буларак та файдаланыла ала. Медицина вертолетлары юл һәлакәтләре, бәхетсезлек очраклары булганда, тиз арада ярдәм күрсәтергә кирәк булганда бик отышлы. «Ансат» җирдән 4800 метр биеклектә, сәгатенә 275 чакрым тизлек белән оча ала. Вертолет кабинасына ике авыру, медицина җиһазлары, шәфкать туташы, табиб иркенләп сыя. Былтыр Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы, беренчеләрдән булып, үзебездә җитештерелгән «Ансат» вертолетын сынап карады. Җитештеру сыйфаты системасы «ISO 9001» стандартларына туры китерелеп эшләнә, бу – эшләп чыгарыла һәм ремонтлана торган техника тиешле контрольдә тотыла, сыйфаты гарантияләнә дигән сүз.

ҺӘР «МАШИНА» ЭНӘ КҮЗЕ АША УЗА

Җыю цехында безне вертолет җыючы, бригадир Илшат Минһаҗев каршы алды.

Әңгәмәдәшем – Арча районының Мөрәле авылы егете. Техника белән кызыксынуы кечкенәдән булса да, төп белгечлегє буенча хисапчы, әмма апасы юлыннан Казан вертолет заводына килгән.

– Зур вертолетларны, хезмәткәрләрнең катлаулы эшен күргәч, башта курку хисе булды. Барысына да өйрәнә алырмынмы, апамның йөзенә кызыллык китермәмме дип тә борчылдым. Остазым – вертолет җыючы Альберт Идрисовның осталыгына карап кызыга идем. Барысы да вакыт белән килә икән, тәҗрибә туплана, куллар күнегә, – ди Илшат.

Тугыз ел дәвамында ул тырыш хезмәте нәтиҗәсендә бригадир вазифасына күтәрелгән. Хәзер бу эштән башка тормышын күз алдына да китерә алмый. «Завод үзе бер дөнья, монда яшибез кебек», – дип елмая.

Цехта 400ләп хезмәткәр, барысы да үз эше белән мәшгуль. Цех кырмыска оясын хәтерләтә. Очкычларны «машина» дип атау гадәткә кергән. Илшат һәр машина янына килеп, аның ничек җыелганын аңлата. Кирәкле кайбер әзер җиһазлар Россиянең башка төбәкләреннән дә кайтартыла. Вертолет кулдан җыела. Илшатның төп эше – гади итеп аңлатканда, вертолет «койрыгын» очкычның төп өлешенә тоташтыру. Бу эш бик төгәл башкарылырга, «койрык» белән төп өлеш бер ясылыкта ятарга тиеш. Ян-якка тайпылыш 0,8 миллиметрдан артса да ярамый. Шуңа да вертолет җыючыга саннар белән эш итәргә, һәр миллиметрны үлчәргә, үткер күзле булырга туры килә. «Койрык»ны тиешенчә көйләп куйгач, клепкалаучы-җыючылар эчке яктан ике эшләнмәне винтлар, гайкалар ярдәмендә бер-берсенә беркетә башлый. Бу үзе бер катлаулы эш. Эшчеләргә көненә 100дән артык гайка борырга туры килә. Сызым буенча һәр болтны үз урынына урнаштыралар, кирәкле урыннарын махсус җайланмалар белән тиешенчә тарттыралар. Клепкаларны пневмочүкеч ярдәмендә сугалар. Бу тар гына «койрык»ның иң киң урынындагы әйләнәсенең диаметры – 80 сантиметр тирәсе. Утырып та, ятып та эшләргә туры килә. Монтажлаучы, электриклар, клепкалаучылар үз эшләрен чиратлап башкаралар. «Койрык»ның эчке ягында буеннан-буена сузылган чыбыклар «пәрәвез оясын» хәтерләтә. Җитмәсә, 14 метрлы «койрык» эчендә эссе. Дөрес, биредә геләр ияләнгән.

– Җәй көне җилләткечләр куябыз. Көньяк Судан ягында командировкада вакытта 60 градус эсседә дә эшләргә туры килде, футболканың коры җире калмаган иде, – дип искә ала Илшат.

Вертолетлар җыелып беткәч, аларны маляр цехына озаталар. Анда кирәкле төскә буйыйлар. Аннары очыш кырында сынап карыйлар. Һәр вертолет меңәрләгән эшче кулы аша уза, заказ бирүчегә барып җиткәнче, энә күзеннән үткәрелә. Ерак арага алып китәргә кирәк булганда, кайбер элементларын сүтеп, самолетка төйиләр. Аннары заводтан җыючы бригада шул илгә вертолетны кабат җыярга бара. Илшатка да шул рәвешле чит илләрдә булырга туры килә.

– Безнең эштә пөхтәлек, зур җаваплылык сорала. Бер дөрес борылмаган винт зур фаҗигагә китерергә мөмкин бит, – ди Илшат.

«УЛЫМ МИН ЯСАГАН ВЕРТОЛЕТЛАРНЫ КҮККӘ КҮТӘРСЕН ИДЕ»

Эш сәгате иртәнге сигезенче яртыда башлана. Дүрт тулып унбиш минутта төгәлләнә. Дөрес, күпләр тиз генә кайтып китәргә ашыкмый. Кайбер көннәрдә кичке сәгать тугызларга кадәр дә тоткарланырга туры килә. «Эшне җиренә җиткереп эшләп бетермәсәң, күңел тыныч түгел»,– ди Илшат. Гаиләсендә аны яхшы аңлыйлар. Шулай булмый ни, хатыны Гүзәл үзе дә шул завод хезмәткәре бит.

Заводның үз ашханәсе дә бар. Күпләр биредә төшке аш ашый, тамак ялгый.

Тавыш арасында эшләгәнгә, вертолет җыючыларга «зарарлы эш өчен» дип өстәмә акча түләнә, социаль пакет, сөт бирәләр. Зыянлы өлкәдә эшләүчеләргә 42 көн ял каралган. Хезмәткәрләргә торак белән тәэмин итүне дә кайгырталар. Предприятие социаль ипотека программасында да катнаша. Шулай ук спорт белән шөгыльләнү өчен дә мөмкинлекләр тудырылган. Фитнеска йөрүчеләргә, эшләү стажына карап, 70 процентка кадәр ташламалар тәкъдим ителә.

Илшат хоккей уйный, волейбол буенча завод чемпионы, Кырымда узган «Бөтенроссия корпоратив уеннар» ярышлары җиңүчесе. Болардан тыш ул һәрдаим кан да тапшыра икән әле. «Мактаулы донор» исемен алырга да озак калмаган. Буш вакытларында балыкка йөрергә ярата. Әңгәмәдәшем бик актив булып чыкты. Завод ел саен эшләү нәтиҗәләре буенча иң яхшы йөз кешене билгели икән, Илшат Минһаҗев та бу исемлектә. Кыскасы, заводның горурлыгы, диләр андыйлар турында.

– Үзебез җыйган вертолетларны күктә күргәч, зур горурлык хисе кичерәм. Иң зур хыялым – улым мин җыйган вертолетларны күккә күтәрсен иде, очучы булсын иде, – ди Илшат.

Эшем буенча да, юлда йөргәндә дә райондашларым белән еш аралашырга туры килә миңа. «Ә, Айдардан Васыйлны беләм, беләм, син шуның кызымыни», – диләр, сөйләшеп киткәч. Безнең районда әтине белмәгән кеше юк, ахрысы, дип уйлап куям мин, андый чакларда әтием белән чиксез горурланып. Әнә шулай күп еллар инде безнең гаиләнең, авылның, районыбызның горурлыгы булып йөри әтием. Кисәк кенә, үзеннән-үзе генә килмәгән бит бу ихтирам. Әбиемнең әти турында сөйләп калдырган хатирәләрдән, әнием истәлекләреннән, безнең янәшәдәге әтиебезнең яшәү дәртенә сокланууларымнан мин бу ихтирамның кайчан, ничек яулана башлавын күргәндәй булам...

ВАСЫЙЛ

Әнә кара чутыр Васыйл (минем әтием шундый сөйкемле кара кеше) күрше малаеның алар капкасына терәп куйган матаен кабызган да авыл буйлап чаба. Аннары кыр юлларыннан җилдертә. Урлап алмаган бит, күрше абыйсы үзе алар капкасына сөяп куйган. Матай кабызганнарын карап торганы бар аның. Бер тәвәккәлләргә кирәктер бит инде. Шушы тәвәккәллеге, техникага хирысдлыгы аны гомере буе ташламады. Авылның мәшәкатьле тормышын техникасын эшкә җигеп җиңеләйткән, әни һәм без кызларын авыр эштән саклап, шул ук вакытта абыйны шуңа өйрәтеп яшәгән икән безнең әти. Әтиебез гомер буе колхозда механизатор, шофер, инженер булып эшләде. Халык телендә әти кебекләргә «тимер җене кагылган», диләр. Безнең әтинең башына бер уй килсә, шуны тормышка ашырмыйча туктамый инде. 2011 елда үзе трактор ясап, хәзер булган буш вакытын шуның янында үткәрә. Инде ишегалдыбыз техника паркын хәтерләтә, шул трактор белән бергә бәрәңге утырткычын, эшкәрткечен, агу сиптерү җайланмасын, печән күтәрү-төшерү җайланмаларын һәм тагын шундый кирәк-яракларын әтиебез үз куллары белән булдырды. Аның оста куллары юк кына, аунап яткан әйбердән дә әллә нәрсәләр ясый, һәркайсына җан өрә.

Әбием хатирәләре аша минем хыялымда тагын чагылып китә әле ул тиктормас, «башлы малай». Дәрестә бер дә тыңлап утырмаган да кебек, кыбырсык бу малайны математика укытучысы тактага чыгара: «Яле, Вәгыйзов, исбатлап бир шушы теореманы». Исбатлый Васыйл, тик китаптагыча түгел. Үз башы белән уйлап, логик эзлеклелектә дәлилләп чыга. «Китаптагыча түгел, ләкин дөрес, болай да була икән», – ди укытучы һәм ничә буын укучыларына легенда сыман, «Ә менә Вәгыйзов болай исбатлаган иде», – дип, теореманың икенче исбатланышын сөйли. Тормышта да әзер, такыр юллар белән бармыйча, үзенчә, үз йөрәге кушканча яшәргә дип шул чакта фикер беркетте микән әллә әтием? Ул мәктәпне тәмамлаган елларда илкүләм төзелешләр гөрләгән вакытлар. Аннары «башлы егеткә» укытучылар да төрле уку йортларына барырга киңәш итәләр. Тик егетнең үз башы, үз уйлары. Беренче уе – солдат каешы бумаган егет егет буламыни, иң башта барып, ил алдындагы бурычны үтәп кайтырга кирәк. Икенчесе, бәлки үзенең уе гына да түгелдер – авылда төп нигездә калып яшәү нәкъ менә Васыйлллары өлешенә төшүен әтиәни сайлый. Өченче уе да бар егетнең. Ул үй шундый татлы, аны гел уйлыйсы гына килеп тора. Бу уенең очы шушы Айдар авылы кызы әниебез Илһамиягә барып тоташа. Тугыз балалы гаиләдә тәрбияләнеп үскән әниебезгә, кияүгә чыкканда, нибары 19 яшь булган. 1982 елда әтиебез белән әниебез гаилә корып җибәрәләр. Әтиебезнең, яратып-көлеп, әнигә: «Мин сине мәктәптән урлап алып кайттым бит», – дип әйтә торган сүзе дә бар әле. Әти-әни сүзеннән чыгуны башына да китереп карамаган әтиебез төп нигездә ата-ана хакы хаклап гомер итте һәм аларның риза-бәхиллеген алып калды. Балалар, болай булыгыз, тегеләй итегез дип, үгет-нәсыйхәт бирүче безнең әти түгел. Гаилә, әхлак кыйммәтләрен ул үз яшәү рәвеше белән күңелгә сеңдереп барган икән. Үзе әти-әнисен хөрмәтләп, безне әби-бабайны яратырга өйрәткән. Әнине ятратканы һәр гамәлендә сизелеп торды, без дә гаилә мөнәсәбәтләренә алардан өйрәнгәнбездер. Кич җитсә, әти кайтмыйча, табын янына утырганыбыз булмады. Каенана-килен мөнәсәбәтләре дә әтинең бик оста дипломат булуы аркасында җайлы гына хәл ителүен дә менә хәзер үземне берьюлы килен, әни, ир хатыны булгач аңлый башладым.

Ихтирамның, дәрәҗәсенең югары булуының сәбәбе әле тагын әтиебезнең тирә-якта оста баянчы, тальянчы булуындадыр. Гармунчыларны бик ярата бит безнең халык. Гомумән, моң белән сугарылган күңел хуҗасы асыл зат инде ул! Хыялым белән әтиемнең алты-җиде яшьләр вакытында шул моң дөньясының ишеген ачкан чагын күзаллыйм...

Олы абыйсы Хариска (инде вафат) гармун алалар. Тик клубка чыкканда да шкафка бикләп китә шул абыйсы кадерле бүләкне. Ялына, ялвара, бабайдан сорап, тәки ачтыра бит кечкенә Васыйл шкафны, тик бабайның шарты: мунчада чыгып уйнасаң гына бирәм, ди. Караңгыдан курка, ялгызы шүрли, ә караңгы мунчада берүзе гармунда уйнарга курыкмый кечкенә Васыйл. Шулай итеп, кача-поса, үзлегеннән, мунчада гармунда уйнарга өйрәнә ул. Безнең өйдә бүген дә гармуннар коллекциясе бар. Әтиебез аларның һәрберсен үз баласыдай кадерләп саклап тота, кичләрен яратып уйный. Балачактан ук гармунчы булу хыялы белән яшәгән әтиебез сәхнәләрдә тальян, баяннарын кулыннан төшермәде. Без кечкенә вакытта гаиләбез белән төрле чараларда, фестиваль-конкурсларда гаилә ансамбле буларак еш катнаша идек. Әтиебез гармун-баянда уйнаса, әниебез белән без җырлый идек. Сәхнәгә, җыр-моңга, сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләгән икән әтиебез мондый чаралар аша. Сәхнә аның өчен ниндидер илаһи бер могҗиза һәм күңел түрендә йөрткән ымсындыргыч хыял да булып яшәде. Шул хыялын әти абыебыз мисалында тормышка ашырды. Бүгенге көндә улы – Марселе үз тамашачысы булган, үз башкару осталыгына ия җырчы икән, димәк, әтиебезнең хыялы да чынга ашты. Абыем яңа бер җырын башкарып күрсәткәндә, әтием тиз-тиз баянын алып ияреп уйнап киткәндә, мин алар арасында илаһи бер моң күпере сузыла башлагандай тоям. Әти дә, абый да бик бәхетле кебек тоела миңа шул вакытта. Әтинең абый иҗатына бик таләпчән булуы да, аны иҗат юлына кертеп җибәрүендә үзен җаваплы тоюындадыр, мөгаен. Әле бүген дә атлаган саен, «Карурман»ыңны җырла, ике тиенлек җырлаучы булып йөрмә», – дип, абыйга тәкрарлап торуын башкача ничек аңлатасың!

Әтиебез соңгы елларда фермадан Теләчегә сөт ташыды. Район үзәгенә көн саен барган кешегә авыл халкының йомышы беркайчан бетеп тормый. Шушы 20 ел эчендә әти күпме кешенең гозерен тыңлагандыр да, кемгә генә ярдәме тимәгәндер. Кайтып капка төбенә туктауга, бар әле, кызым, фәлән апаңа менә моны тапшыр, дип җибәргән әти дә шулай безгә кешелеклелек дәресләре биргән икән. Хәзерге көндә үземнең дә берәр кешегә ярдәмем тисә, булыша алсам, мин чын күңелдән сөенәм, чөнки кечкенәдән, әти, синең беркемне дә кире бормыйча, үз эшеңнән бүленеп, булдыра алганча кешегә ярдәм итүеңне без күреп үстек. Кешеләрне яратырга, аларга игътибарлы булырга, гамьле булып үсәргә өйрәткәнсең безне.

Гаиләдә без – абыем, апам һәм мин – нинди генә хәлләр булса да, әнигә елышып үстек. Ә әниебез, бик хәйләкәр генә итеп, әтиебезгә юнәлтә иде, бармый чараң юк! Шулай итеп, ул безнең каршыбызда ата хакын күтәргән. Каядыр барасы булса, әтиегездән сорагыз, берәр кыек эшең беленсә, әтиеңә әйтәм, дип, гел безгә әтиебезне үрнәк итте. Баланың атага булган мәхәббәте дә ана йөрәге аша килә, ди бит. Мин моның серен үсә төшкәч аңлый башладым да кебек, иң элек әтиебезне олылаучы, аны зурлаучы әбиебез иде, чөнки татар гаиләсендә ир-ат элек-электән зур хөрмәткә лаек, шуның бәрабәренә гаиләләр дә нык булган, балалар да ятим калмаган.

Еллар үтә тора, менә инде без дә, һәркайсыбыз үз куышын – гаиләсен булдырды, түгәрәк тормышта яшибез. Болар барысы да – әти-әние-

Син безгә маяк

...Авылда гомер кичерүче газиз әнием белән кабат хушлашып, кайту юлына кузгалдым. Март аеның азаклары булуына карамастан, көннәр язга юл бирергә бик ашкынып тормыйлар әле. Көндезләрен кояш югарыга үрмәләсә, төннәре һаман салкын.

Бүген дә ябалак-ябалак кар ява. Тагын бар җиһанны аклык каплады... Нәкъ мәрхүм әтием яраткан алмагачларның ап-ак чәчкәләре сыман. «Алмагачлар чәчәк ата майның унбишләрендә», – дип җырлыйлар. Минем әтиемнең туган конендә дә шулай бар дөнья аклык-пакьлеккә күмелә. Һәр елны шулай. Тик әтиебез генә бу матурлык белән хозурлана алмый. 2013 елның октябрь аенда рәхимсез авыру аны арабыздан мәңгелеккә алып китте.

Кукмара районы Олыяз авылында Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы Максут Заһретдин улын өлкән буын кешеләре бик яхшы хәтерли. 1969 елның салкын көзендә ул Олыяз авылы җирлеге халкына чын мәгънәсендә мәгърифәт учагы кабызучы булган, дип әйтсәм дә, ялгыш булмастыр: бирёдә октябрь аенда яңа матур бинада сигезьеллык мәктәп эшли башлый.

Безнең нәселебездә гомуми укытучылык стажы 230 еллап чорны үз эченә ала. Әтием әнием, абзыйларым, апа-абыйларым һәм мин үзем. Оясында ни күрсә,очканда шул булыр, ди халык мәкале. Акыллы фикерле,тырыш,туры сүзле,җитди һәм зыялы, үткен карашлы, зифа буй-сынлы әтием әлеге мәктәптә 30 елдан артык директор булып эшләде, мөгаллим буларак, балалар күңелендә география фәненә кызыксыну уятты. Бик күп авырлыкларны җиңеп, үз куллары белән нигез ташларын салган белем учагында эшләү дәверендә аңа күпне күрергә туры килгәндер. Әмма бервакытта да әтием хезмәттәшләренә авырлык китерергә тырышмады, һәрвакытта ярдәм кулын сузарга омтылды. Озак еллар җитәкче урында эшләсә дә, аның беркайчан да без – өч бала өчен вакытым юк, ярдәм итә алмыйм дигәнен хәтерләмим.

Гомерләр аккан су кебек тиз үтә. Әтиебезнең 80 яшьлек юбилеена бик күп кунаклар килде, матур котлау сүзләре яңгырады, хезмәте югары бәя алды. Шат йөзле, җор сүзле, киң күңелле әтиебез күпләрнең хәтерендә шундый булып калгандыр. Озак та тормый ул, гомер иткән тормыш иптәше, хезмәттәше булган әниебез Гамиләне калдырып, бакыйлыкка күчте. Ләкин куанычлы хәбәрләр белән китте, чөнки тиздән өр-яңа мәктәп ачылачак иде!

Тиздән җиргә тагын май ае килер, алмагачлар шау чәчәккә күмелер. Күңелләрне кузгатып, күзләрне яшь тамчылары каплар.

без тырышлыгы, чөнки алар нинди генә эшкә тотынсалар да, барысы да безнең өчен дип, безнең хакка дип эшләнә. Тормышта нәрсәгә дә булса ирешкәнбез икән, монда әтиебезнең өлеше бик зур. Ул – безнең зур таянычыбыз, ныклы терәгебез, ярдәмчебез. Әниебез дә – безнең кебек, әтиебезнең киң җилкәсе артында аңа зур ышаныч белән яши. Әти белән әнидә кояш җылылыгы да, йолдызлар нуры да бар. Ачулансалар да, шелтәләсәләр дә, без ул илаһи затларга ачу һәм үпкә сакларга тиеш түгел, чөнки аларның шелтәле сүзләре дә без әйбәт булсын өчен әйтелә. Күңелләребездән, күз алдыбыздан аларның нурлы йөз сурәтләре китмәсен, югалмасын иде. Гомеребез буе әнкәй, әткәйләрнең җылы карашлары безне озата барсын иде.

Тормышта төрле хәлләр була, безнең гаиләгә дә сынаулар аша узарга туры килде. Абынасыңны белсәң, юлыңа салам түшәп куяр идең, ди бит халык. 2015 елның гыйнвар аенда, аяк астыннан бәла чыгып, иртәнге хуҗалык эшләрен карап йөргәндә, әтиебез таеп егыла. Каты һәм җайсыз төшкәнлектән, тиз арада сул кулы йөрмәскә әйләнә. Табиблар, кичекмәстән, Казанга барырга кушалар. Яңа ел яллары үзенекен итә, тиешле урында тиешле белгечләр булмау сәбәпле, операция 6 сәгатьтән соң гына ясала. Табиблар әтиебезнең сул кулын кисү вариантын да искәрттеләр. Катлаулы операция, Аллага шөкер, уңышлы уза. Төп артерия өзелү сәбәпле, әтиебезнең гомере дә кыл өстендә булуын операция ясаган табиб безгә соңрак әйтте. Менә шулай, безнең бәхеткә исән калды әтиебез. Кулы да исән-сау, тальяннарын, гармун-баяннарын да уйный. Ә мин болай уйлыйм: гомере буе әти-әнисе хакын, туган җир, туган ил хакын, гаилә хакын хаклап яшәгән әтиебезне ата хакы исән-имин саклагандыр. Бик зур бит ул ата хакы. Аңарда әтинең үз изгелекләре дә, безнең аны яратуыбыз да, туганнарының хөрмәте дә, әнинең аны хаклавы да.

Раилә ВӘГЫЙЗОВА-ФӘСХИЕВА,
Теләче.

Үткәндә калган әтиле якты көннәр, бәхетле балачак, үсмерлек еллары, тормышка чыгу, оныклар белән сөенгергән көннәр искә төшәр. «Бабам шикелле буласым килә минем!» – дип, укытучылык һөнәрен сайлаган яраткан төпчек оныгыңны күрсәң, ничек куаныр идең син!

Әткәй! Ераклардан безне күзәтеп, безгә изге теләкләр теләп торасың кебек. Күктәге иң якты йолдызның да берсе син кебек тоела. Рәхмәт сиңа, Әткәй! Изге күңелең, кылган яхшы эш-гамәлләрең өчен мең-мең рәхмәт! Безгә мәңге маяк син! Бик сагынып, төпчек кызың.

Светлана САДЫЙКОВА,
Казан.

Кендек каны кайда саклана?

Моңа кадәр әлеге сорауны башыма да керткәнем булмаган икән. Сабый дөньяга аваз салганнан соң соңгылык юкка чыгарыла дип белә идем, аның нинди үзлекләргә ия икәнлеген, киләчәктә ничек файдаланырга мөмкин булуын да уйламаганмын хәтта. Әмма Казан федераль университеты клиникасы базасында эшләүче Биобанктан шактый кызыклы мәгълүматлар белән кайттым.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Биобанк лабораториясендә җиде төрле криосаклагыч урнаштырылган. Аларда кендек канының өлгермәгән күзәнәкләре (стволовые клетки), ясалма орлыкландыру өчен сперматозоидлар һәм күкәй күзәнәкләре, тикшеренүләр өчен биоматериаллар саклана. Шунысы да мөһим: биредә барысы да автоматлаштырылган. Саклагычларда түбән температура торсын өчен, белгечләр аларны сыек азот белән интернет аша гына тутырып тора. Мондагы үрнәкләрнең саны сер булып кала. Ә менә биоматериаллар нинди максатларда сакланыла һәм Татарстанда әлеге хезмәттән файдаланучылар күпме? Шушы һәм башка сорауларга безгә табиб **Эльмира Елагина** бик теләп җавап бирде.

– Биредә сакланыла торган иң кыйммәтле биологик материал – кендек каны. Күзәнәкләр яшь, өлгермәгән булганлыктан, алар гаҗәеп үзлекләргә ия. Мәгълүм булганча, сабый дөньяга аваз салгач, кендек һәм соңгылык күп очракта юкка чыгарыла. Совет заманында алар гормональ препаратлар ясар өчен фармфабрикаларга тапшырылган. Әмма нәкъ менә шушы биоматериал яңа туган бала өчен үзенчәлекле медицина иминиятләштерүе булып тора да инде. Ягъни бүген кендек каны онкологик авырулар вакытында химия һәм радиотерапиядән соң, сөяк миен (костный мозг) күчереп утыртканда альтернатива буларак файдаланыла. Элек гәүдә авырлыгы 30 килограммнан артмаган балаларга гына күчереп утыртырга мөмкин булса, хәзер бик тә охшаш ике үрнәкне алып, хәтта урта яшьләрдәге кешеләргә дә файдаланырга мөмкин. Сөяк миен күчереп утырту – бик катлаулы процесс. Кешенең иммун системасы чит күзәнәкләрне кабул итми, ә иң уңышлы туры килә торган донор материалын күп очракта бик якын туганнардан гына алырга мөмкин. Шуңа күрә баланың кендек канын саклау бик мөһим. Үрнәкләрнең тагын бер төре – операция вакытында кисеп алынган яман шеш, башка төр авырулар белән зарарланган күзәнәкләр, тукыма үрнәкләре. Алар яңа дару препаратларын уйлап чыгару һәм терапияне яхшырту максатыннан алып барылган эзләнүләр өчен кулланыла. Моннан кала, Биобанк киләчәктә башка төр биологик материаллар да сакланылачак. Алар реконструктив һәм пластик хирургиядә кулланыла торган донор үрнәкләре – сөякләр, кимерчәк һәм тән тиресе. Бик түбән температурада сакланыла торган әлеге биоматериаллар авариядән соң ясалган операцияләр вакытында, онкологиядән зыян күргән әгъзалар һәм тукымалар алынган очракта һәм башка җәрәхәтләр һәм кимчелекләр булганда файдаланырга мөмкин.

– Аңлавымча, сабыйның кендек канын сакларга карар кылган әти-әни лаборатория белән алдан ук килешү төзергә тиеш була.

